

# Автордан...

Икебез дә бер районда туып үссәк тә (әле бер үк елны туганбыз), мин Вафирә Гыйззәтуллина белән якыннан таныш булмадым. Ул – талантлы җырчы, Татарстан һәм Каракалпакстанның халык, Россиянең атказанган артисты, мин – гади бер авыл укытучысы. Шулай да, миңа аны берничә мәртәбә күрү бәхете елмайды.

Тәүге очрашу 1985 елда М.Җәлил исемендәге опера һәм балет театрында зур бер концертта булды. Безне, төрле районнардан килгән авыл советы рәисләрен (берара авыл башлыгы булып эшләгән идем), озын-озак җыелыштан соң, ял иттереп алу өчен, концертка алып барганнар иде.

Менә ул сәхнәгә чыкты. Өстә – килешле ак күлмәк, аякта – ак түфлиләр. Әллә шушы аклыктан, әллә җырчының нурлы түгәрәк йөзеннән тирә-як бер мәлгә яктырып китте. Зәңгәр күктән, җырчыны күрергә дип, тулган ай үзе сәхнә түренә килеп кергәндәй булды.

...Зал буйлап моң агыла. Килешле, тыйнак хәрәкәтләр ясап, кирәк урында биеп тә китеп, башкарган җырын ямьгә, гүзәллеккә төреп, җырчы, сандугач сайравына тиң тавышы белән, безгә, тамашачы күңеленә, наз, ләззәт өләште, пакълык-сафлык хиссияте күңелләрне әсир итте. Шәхсән мин, күңелем белән нәкъ шундый хис-тойгылар кичердем һәм якташ җырчыбыз өчен сөенеп тә, горурланып та утырдым.

Икенче юлы 1987 елның җәй башында Менделеев каласының “Коммуна” театрында күрештек. “Ядкарь” әдәби-музыкаль берләшмәсе (җитәкчесе шагыйрь Марсель Гыймазетдинов) Халыкара балаларны яклау көне уңаеннан кичә оештырган иде. Без, ягъни, мин һәм “Кама колхозының” ул вакыттагы партком секретаре Мөхәммәтнур Сабитов кичәне алып баручылар идек. Бәйрәм кунаклары арасында Вафирә Гыйззәтуллина әнисе Бәдерниса апа белән иде.

Шушы кичә турында районның “Октябрь байрагы» газетасында (2 июнь, 1987 ел) корреспондент М. Хафизова язып чыккан “Ана һәм бала” дигән мәкаләсеннән өзек: « ... Бу көннәрдә Вафирә үзенең иҗатының гөрләп чәчәк аткан чакларын кичерә, күңеленең иң ашкын хисләрен тамашачыларга бүләк итеп “Әнкәй”, “Туган авылым” җырларын башкара.

Әнкәй, әниләр... Әйе, бу дөньяда яшәвебез өчен без барыбыз да әниләребезгә бурычлы. Әниләр... Вафирәнең әнисе дә үзебезнең районда Камай авылында яши. Мөхәмәтдин ага белән Бәдерниса апа сигез бала – өч ул һәм биш кыз – үстерделәр. Биш кызның бишесе дә җырлый. Ләкин Вафирә уздыра төште. Нәкъ җырдагыча, ана бүген биш кайгысы һәм биш шатлыгының бәхеткә әверелүен күрә. Шул җырлы йорттан чыгып, ерак илләр, юллар аша үтеп, биек мәшһүр сәхнәләргә менеп, кыз әнисен җыр белән иркәли.»

Алга таба үзебездә, Бәзәкә клубында очраштык без. Авылдашыбыз шагыйрь Марсель Гыймазетдиновның вафатыннан соң 50 яшен билгеләп үткән кичәдә чыгыш ясады һәм җырлады ул. Әлеге искә алу кичәсе турында “Менделеевск хәбәрләре” газетасы менә нәрсәләр язган иде. ( Корреспондент Р. Булатова, “Кеше китә – җыры кала” , 2 декабрь, 1993 ел)

«...Шагыйрьне якташыбыз, популяр җырчы, җөмһүриятнең танылган артисткасы Вафирә Гыйззәтуллина белән зур иҗат дуслыгы берләштерде. Үзенең дусты Марсель Гыймазетдинов турында ул җылы һәм тәэсирле итеп сөйләде. Аның

чыгышының тик бер өлешен генә китерәм: “Үлем сорап тормастан безнең арадан көчлеләрне, яхшыларны чүпли бара. Ләкин без, иҗат кешеләре, шигырьләребездә, җырларыбызда яшәвебезне дәвам итүебез белән бәхетле”. Моңараслау итеп, ул үзенең Гыймазетдиновка багышланган үтә нәзберек һәм нәфис “Тагын кайттым” шигырен укыды. Вафирә Гыйззәтуллина Марсель Гыймазетдиновның үзенә бик күп шигырьләрен, җырларын җибәрүен әрнеп һәм үкенеп искә төшерә. Ә аңа ул чакта боларны башкарырга нидер комачаулый. Бу хакта артистка һәрвакыт үкенеп искә алачак. Һәм киләчәктә беренче чиратта М. Гыймазетдинов җырларын җырлаячагын ант иткәндәй ышандырды ул.»

Бу урында җырчының шагыйрь М. Гыймазетдиновка бүләк иткән һәм миндә сакланган буклетын тәкъдим итәм. (- Р.М.)




Соңгы мәртәбә Вафирә Гыйззәтуллинаны кабат Менделеев каласында күрү насыйп булды. Һәр елны район мәгариф һәм мәдәният бүлекләре язгы каникулларда укучы балалар арасында “Сандугачкай” дип аталучы җыр бәйгесе уздыра. Менә шул чарага бер елны В. Гыйззәтуллина һәм Туфан Миңнуллин килгәннәр иде. Алар жюри составында түгел, ә зал уртасындагы рәтләрнең берсендә, балалар арасында утырдылар.

Бу бәйгедә безнең мәктәптән үзем оештырган “Кызыл розалар” исемле вокал төркеме уңышлы чыгыш ясап, авыл мәктәпләре арасында I урынны яулаган иде.

Нәтиҗәләр ясаганда, В. Гыйззәтуллина, сәхнәгә менеп, әлеге бәйгегә, катнашучыларга үз фикерләрен җиткерде. Безнең җырчы кызларыбызга: “Матур җырлавыгыз, татар җырларын пропагандалавыгыз өчен зур рәхмәт, алга таба да шулай дәвам итегез”, -диде.

В. Гыйззәтуллина белән бөтен танышлык менә шул. Хәер, таныш булуыбыз моның белән генә чикләнмәгән булып чыкты.

Мин мәктәбебездә егерме елга якын җыр дәресләре алып бардым, музыка буенча махсус белемем булмаса да. Авыл мәктәбендә җыр дәресләре урта сыйныфларда бары 4 сәгать кенә. Соңга таба аны да 3 сәгатькә калдырдылар. Бу 3 дәрес өчен махсус белемле укытучы авылга эшкә килми. Шунлыктан дип уйлыйм, пионервожатый булып эшләвемне дә искә алып, бу дәресләрне миңа бирделәр.

“Махсус белемем юк”,- дип, үзең белгән җырларны гына өйрәтеп, дәрес уздырып булмый. Дәресләремне кызыклы да, мавыктыргыч та итү максатыннан, мин өстәмә материаллар җыя башладым. Татар җырчылары, композиторлар, гармунчылар, якташлар турында нинди материал күрәм, табам – барысын җыя барам. Алар арасында, бигрәк тә үзебезнең районнан чыккан, танылган кешеләр турындагылары минем өчен аеруча кадерле иде. Еллар дәвамында тупланган “багажым”да якташыбыз В. Гыйззәтуллина турында да байтак кына язмалар, истәлекләр җыйналды. Шушы табышларым аша мин Вафирә белән тагын да якынрак таныштым.

Шулай итеп, җыйналган бу кыйммәтле истәлек-ядкарьләр (пластинкалар, магнитофон язмалары, газета-журналлар мәгълүматлары, җыр китаплары һ.б.) ярдәмендә һәм олпат шагыйрьләребез, мәшһүр җырчыларыбыз иҗаты аша татар халкының көй-моңнарын балаларга ишеттерергә, милли моңның кабатланмас әһәңен, назын-ләззәтен алар күңеленә җиткерергә, туган телебезгә, милли сәнгатькә, татар халкының тарихына, аның җыр-моң хәзинәсенә мәхәббәт һәм горурлык, ихтирам һәм хөрмәт хисләре тәрбияләргә тырыштым. Күпмедер дәрәҗәдә моңа ирештем дип әйтә дә алам. Чөнки төрле кичә-концертларда, җыр бәйгеләрендә укучыларыбыз, уңышлы чыгышлар ясап, күп мәртәбәләр призлы урыннар яуладылар. Үзем дә, 1995 елда, укытучыларның район бәйгесендә (барысы IV тур) катнашып, җыр фәне буенча чит мәктәптә, чит класста мәртәбәле комиссия алдында ачык дәрес күрсәттем, “Ел укытучысы” дигән исем алдым.

Лаеклы ялга киткәч тә, җыелган язмаларны ертып атмадым, мичкә якмадым. 2001 елда, В. Гыйззәтуллинаның фаҗигале вафатыннан соң, бәлки аның турында, үземдә булган материалларга нигезләнеп, берәр кечерәк кенә булса да китап чыгарырга кирәктер дигән уй килде башыма. Әмма бу эшне һаман суза килдем. Инде җырчының 70 еллыгы якынлашкач, ныклы карар кылдым. Кирәк!

Һәм менә ул кечерәк кенә, әмма җырчы турында бик урынлы, мәгънәле бәяләмәләр, ихлас күңелдән әйтелгән җылы сүзләр, тирән фикерләр тупланган китап. Китапта, кереш сүздән кала, мин язган истәлекләр юк диярлек. Биредә В. Гыйззәтуллина турында, иң беренче чиратта, җирле шагыйрьләребез, аның туганнары, сәнгатьтәш дуслары, аның җырларына гашыйк булганнар һәм танылган шәхесләрнең җырчы үзе исән чагында ук һәм вафатыннан соң иҗат иткән шигырьләре, истәлек-ядкарьләр, хатирәләр урын алды.

Йөз-битенә, киенү-бизәнү, сәхнәдә үз-үзен тоту, җыр башкару рәвешенә карап, аны берәүләр гүзәл кош – аккошка, кемнәрдер өрфия канатлы күбәләккә охшатты, тулган ай, якты йолдыз, челтер чишмә диючеләр булды. Ә мин аны кыю, батыр, тәвәккәл булуы өчен бөркеткә тиңлим. Бөркетләр очарга яратылган, аларның урыны биектә, таш кыя тауларда, төпсез упкыннар өстендә, колач җитмәс күкләр киңлегендә. Ут-яшеннәр, җил-давыллар канатларын каерган чакларда да көчле, горур, башимәс булып кала алучы бөркеткә тиң иде Вафирә.

Искә төшерик. 1990 елларда милләт язмышына битараф булмаганнар белән бергә В. Гыйззәтуллина мәйданнарга чыга. Ил, тел, дин язмышы өчен борчылып, урам җыеннарында “Без көрәшмәсәк, кем көрәшер?!” шигаре белән ялкынлы нотыклар сөйли. “Ком бураны” җырын яшел әләм итеп күтәрә, татар халкын азатлык, бәйсезлек өчен көрәшкә чакыра. Шул көннәрдә Вафирә кыю да, хәтәр дә адымга бара: Россиянең атказанган артисты дигән таныклыгын Ирек мәйданында... учакта яндыра! Мондый тәвәккәллекне, кыюлыкны теләсә кем булдыра алмый.

Иманы нык, әхлагы көчле кеше генә эшли ала моны. Бу кеше – Вафирә! Безнең Вафирә!

**Вафирәгә – якташлардан шигъри бүләк.**

***Марсель Гыймазетдинов***

**Тыңлар идем мең кат.**

Тыңлар идем мең кат шул моңнарны
Күңелемә якын, якыннар.
Вафирәнең йөрәгеннән ашкан-
Газиз миңа, газиз ул җырлар.

Язларда гына сандугач
Бигрәк тә моңлы була.
Сандугачлардан да моңлы-
Вафирә Гыйззәтуллина.

Җырлап узсаң әгәр гомер юлың,
Картаймассың, күпме яшәмә.
Синең җырлар, дустым Вафирәкәй,
Юлдаш булсын безнең яшьләргә.

***Илгиз Абдуллин***

**Җырларында татар иле**

Камай чишмәсе чакыра
Туган авыл таңына.
Туган якның моң-зарлары
Иңгән аның җанына.

Күңелендә сагынулар,
Туган якны ярата.
Йөрәге – җырлар чишмәсе,
Җырчы таңнарга кайта.

Татар илен җыры белән
Күтәрде ул иңенә.
Җыры бара моңы белән
Кыйтгаларга илче булып
Данлы татар илендә.

***Рафаэль Җәлилов***

**Ишетелә моңлы тавышың.**

Әй, Зиләйлүк, Бондюг кызы,
Җырга күчкән чибәр, сылу кыз.
Әле һаман сине онытмыйбыз,
Синең җырны һаман җырлыйбыз.

Еракларданкилгән көннәр, еллар аша
Ишетелә моңлы тавышың
Шул моңнарда – синең шатлыгың да,
Шул моңнарда – синең сагышың.
Бондюг хәзер Бондюг түгел инде,
Бондюг хәзер матур, зур кала,
Шәһәр хәзер Бондюг диеп түгел
Менделеев диеп атала.

Өйләр башка, урамнар да башка,
Җырлар башка, көйләр башкалар:
Синең хыялларың, өметләрең
Тормышыңа инде ашалар.

***Камил Динмөхәммәтов сүзләре,***
***Рәшит Шәяхмәтов көе.***

**Камаем – яшьлегем бишеге**

Камаебыз аша уза
Әби патша юллары.
Күңелдән китми һичкайчан
Туган ягым моңнары.
**<u>Кушымта:</u>**
Синдә ачтым моңнар ишеген,
Камаем – яшьлегем бишеге!

Кылдый урманнарын бизи
Назлы, бөдрә ак каен.
Сихри моңнарга чолганып
Яшә, минем Камаем.
**<u>Кушымта.</u>**
Өздереп сайрый кошлар да
Кылдый урманнарында.
Кушыла сыман шуларга
Вафирә моңнары да.
**<u>Кушымта.</u>**
Үтә дә моңлы уйныйлар
Камайда гармуннарны,
Әйтерсең, монда җыйганнар

Дөньядан бар моңнарны.
**Кушымта.**
Хәтердә туры юлларың,
Онытмыйм чатларың да,
Җырлыймын шушы җырымны
Сагынган чакларымда.
**Кушымта:**
Синдә ачтым моңнар ишеген,
Камаем – яшьлегем бишеге!

***Роберт Нәбиуллин***
**Синең җырың – чишмә.**



Хәтфә юлларны еллар яшергән,
Безнең эзләргә чәчәкләр үскән.
Назлы тавышың, сүнмәс сагышың,
Чишмә теленә җыр булып күчкән.
Урманга керәм, чишмәгә киләм,
Без аның суын бергәләп эчкән.
Серле күзләрең, назлы карашың,
Җыр белән бергә чишмәгә күчкән.

***Камил Гыйльмуллин***
**Аккошлар китә**
***(Сөекле авылдашым, сандугачтай җырчы***
***Вафирә Гыйззәтуллина истәлегенә.)***

Күз иде. Аккошлар китә
Туган күлләрен ташлап.
Ә без күл буенда идек,
Син әйттең сүзең башлап:

Китмә, китмәгез аккошлар!
Сез киткәч күңел китек,
Чит илләрдә, ят җирләрдә
Яшәрсез ничек итеп?!

Бу уеңны җырга салып
Яңгыраттың дөньяга...
Аккошлар булып киттең син,
Елгалар синсез ага.

Синсез чишмәләр челтери,
Синсез ятим урманнар.
Сагына сине татар халкы,

Сагынабыз – туганнар.

Кеше китә - җыры кала!
Дөрес әйтәдер халык.
Моңыңны халкың йөртәдер
Йөрәк түренә салып.

***Саймә Гыйльметдинова***

Әнкәң белән бер үк туфракта без
Тәүге сулышыбызны алганбыз.
Тәпи китеп шунда, тел ачылып,
Беренче адымнарны алганбыз.

Сөйгән әнкәң – Бәдерниса апа
Абалачта туып үскән бит.
Кырларында, яшьли, урак урып,
Чишмәләре суын эчкән бит.

Нәсел җебе тартып кайтаргандыр,
Еш кайттың син әнкәң авылына.
Моңлы тавышың белән сәхнәләрдән
Җырлар бүләк иттең халкыңа.

Узган ел да Сабан туйларына
Әнкәеңне сагынып килгәнсең.
Тоеп гүзәллеген табигатьнең,
Ул йөргән эзләрдән йөргәнсең.

Язгы тургай, сандугачлардан да
Моңлы булды синең тавышың.
Күпме җырлар җырланмыйча калды,
Үкенечле булды язмышың...

Авыр кайгы сарган туган ягың,
Сагышлана урман-кырларың.
Кыска гомереңнең истәлеге –
Калдырып киттең гүзәл җырларың.

Үз халкыңның бәхете өчен янып
Гаделлеккә табынып яшәдең.
Мәйданнарга чыгып, ирек даулап,
Яшен уты булып яшьнәдең.

Туган ягың сиңа канат бирде,-
Сөйгән авылың булды уеңда.

Бүген сине тәүге аяк баскан
Газиз җирең ала куенына.

***Гайшә Сәгъдиева***

Күрәчәкнең ничек буласын
Алдан әйтә алмый беркем дә.
Язмышыңа булган тәкъдирне
Тормышка ашыра бер көндә.

Ул көннең дә бер мизгеле
Кала җитеп кеше башына.
Әллә сизенгәндәй кеше
Шул язмышка үзе ашыга
Килер өчен үлем каршына.

Их, Вафирә, шактый кешеләргә
Бик күп изгелекләр иттең син,
Ышанып та булмый үлемеңә,
Әллә инде исән киттең син?

Нурлы йөзең китмәс күз алдыннан,
Матур тавышың чыңлар колакта.
Күз яшьләрен булмый туктатып,
Ничек кенә сабыр булсак та.

“Китмә, китмә, сандугач”
Мәңге сайра безнең арада,
Сәхнә бакчасында ояң көтә
Юксынарбыз сине шуңа да.
(Ә нигәдер,
сайрыйсыәдыр кебек һаман да).

Синдәй шәхес мәңге яши,
Тормыш юлың якты маяклы.
Таң йолдызы кебек балкыдың да
Иртә сүндең нигә шулчаклы?

Синең җаның сүнмәс йолдыз
Булыр галәм күгендә.
Бар дусларың сагынып искә ала
Җырлавыңны тыңлап бүген дә.
Үз талантың белән танылып
Үлмәс булып калдың гомергә.

*Рәмзия Мөхетдинова*

**Бөркет йөрәкле былбыл.**

Былбыл – талда,
Ә Вафирә – залда
Өзеп-өзеп сайрыйлар.
Моңлы тавыш,
Татлы сагыш
Күңелләрне айкыйлар

Ирек даулап,
Тел, милләтне яклап
Булдың гүя җил-давыл.
“Ком бураны”ң
Яуга чакыру булды,
Бөркет йөрәкле былбыл.



Очтың аккош,
Алда, диеп, ак кыш.
Җан авазың кочты күк.
Чыкмас истән,
Төшмәс телдән –
Бондюг кызы Зиләйлүк.

Якташларыбызның Вафирә Гыйззәтуллинага багышланган әлеге шигырьләре “Менделеев яңалыклары” газетасында төрле елларда басылып чыктылар.

*Разил Вәлиев*

**Җыр бәйрәме, моң бәйрәме бүген...**

Мең тугыз йөз алтмыш бишнең көзе... —
Ул кич әле һаман хәтердә...
Илаһи йорт — Тукай клубында
Яшь кыз җырлый, җырлый Вафирә.

Бер кайгысыз идек әле генә, —
Сизми калдык күңел тулганны,
Сизми калдык шул кич моңлы җырга —
Вафирәгә гашыйк булганны.

Дөнья гаме бары моңлы җанда,
Моңлыларга бирсен чыдамлык.
Аның моңы таш бәгырьгә төшсә,
Ташны ярып шытып чыгарлык.

Килми бәхет елап чакырганда,
Килми ирек сыктап, зарланып...

Җыр авазы — азан авазыдай,
Биек аның изге мөнбәре.

Бүген аның моңлы туенда без, —
Сизми калдым күңел тулганын;
Сизми калды халык, ничәнче кат
Вафирәгә гашыйк булганын.

Җыр-бәйрәме, моң бәйрәме бүген, —
Бу кич калыр мәңге хәтердә.
Оныттырып бөтен кайгыларны
Бәхет җырын җырла, Вафирә!

***Гөлнур Айзат***

**Вафирәне күрдем**

Вафирәне төштә күрдем бүген,
Нигә миңа килеп кергәндер.
Я җырларын,я үзен дә бераз
Искә алмаганга күрәдер!
Өсләрендә алсу җилле күлмәк-
Канатлары очып китәрлек!
Миңа таба көлеп карап килә
Кулларына нидер күтәреп.
Үзе җырлый һаман шул"Бәхет"не,
Матур ыспай чәчләр шул көе.
Бер канаты гына сүтелә төшкән,
Сызылып киткән азрак бер җөе.
Ә мин хушым китеп карап торам-
Сылулыгы -шул без ах иткән!
Атлап түгел,йөгереп килә никтер-
Алсу күлмәк,гүя,ак җилкән!
Килеп җитте,кулларында -Коръән-
Белмим,бусы-кемгә бүләге?
Һәм мин шунда кинәт уяндым да,
Белми калдым аның теләген...

***Саҗидә Сөләйманова***

Син булган җирдә
Бар донья
Коена нурга
Кинәнә җырга,
Вафирә!

Вафирәнең үз шигырьләре белән дә танышып узыйк.



***Вафирә Гыйззәтуллина,*** *"Аргамак" журналы № 9, 1994.*

**НӘГЪЛӘТ**

Туганнар кырылыша бүген -
Якын дуслар алдаша.
Милләтләр бер-берсе белән
Кан телендә аңлаша.
Я, Ходаем, бир сабырлык
Җиремә, милләтемә.
Көймәбез килеп терәлде
Алланың нәгъләтенә.
Шартнамә дип алдыйталдый
Шартлыйлар инде бүген.
Кайгы-сөрем биләп алды
Татарстанның күген.
Кемгә ышанырга белми
Мескен кол булган халык.
Тыпырчына тегендә-монда -
Нәкъ кармактагы балык.
Селәү сибеп каптыралар
Кармакларга үзеңне.
Әй, татарым, акылыңа кил
Зуррак ач күзеңне.
Телсез-денсез калдырдылар,
Инде илсез калабыз.
Шартнамәгә кул куеп без
Башны утка салабыз.
Үзе теләп кол була бит
Горур, мәгърур милләтем.
Милләтен сатучыларга
Шигырем булсын нәгъләтем
нәгъләтем
нәгъләтем...

**САГЫНЫРСЫЗ ӘЛЕ.**

Муеныма асыл ташлар тагалмадым -
Байлык җитмәде.
Татар түрәләре мине күралмады,
Рәнҗетте вә үз итмәде.

Ләкин аңа карап мин һич сыгылмадым.
Абынмадым аяк чалганда.
Азатлык дип янар тәнем-каным
Хәтта газраил җанымны алганда.

Сагынырсыз әле кызыгызны,

Сандугачка мине тиңләрсез.
Вафирәдәй безнең гөлләр диеп
Елый-елый сулар сибәрсез.

**Танылган шәхесләрнең сүзләренә колак салыйк.**

***Разил Вәлиев*:**

...Гыйззәтуллинаның* берсен
**Кояшка** тиң күргән Тукай.
Кояш булгач, Ай да кирәк:
Кайда ул Ай? –
**Ай** син бугай.

** Беренче татар театр артисткасы Сәхипҗамал Гыйззәтуллина-Волжская.*

***Мөхәммәт Мәһдиев*** аны: **"Көмеш чыңлы кыңгырау", -** дип атады.

***Флера Сөләйманова:"*** Минем кулдан тотып, Вафирә мине кадрлар бүлегенә алып керде, сөйләште, аңлатты. Шуннан соң миңа Атказанган артист исеме бирделәр. ***Иманлы кеше*** иде.

***Илһам Шакиров***: "**Талант".** Ә талант – аккан су. Үзе юл ярып барса, аны тыя алмыйсың.

***Әбрар Кәлимуллин***: "Вафирә – **сирәк кеше"**.

**Телеэкраннарда яңгыраган фикерләр:**

- Вафирә, агымсыдай ташып-ургып, күңелләрне назлап торган талант иясе иде.
- Бүгенге моңсыз заманда сәхнәдәге матурлыгы, үз-үзен тотышы, гримы, кигән киемнәре – татар сәхнәсе эталоны.
- Чибәрлек, матурлык, нәзакәтлелек балкышы белән безне дә балкыта иде.
- Гади, эчкерсез, чая, оптимистик рухлы булды.
- Сабырлыгы, зирәклеге, акыллы-мәгънәле сүзләре белән күңелләрне яулады.
- Саф тавышлы. Ә нечкә күңеленең төпкелендә көч ятты.
- Туры сүзле, кыю, тәвәккәл, үз-үзенә нык ышанган кеше иде.
- 1990 елларда лидерлык сыйфатлары ачылды. Татар халкының иреге, азатлыгы өчен көрәштә "Ком бураны" җыры корал рәвешендә булды.
- Ике канатлы иде ул. Бер канаты – җыр булса, икенче канаты – көрәш, бәйсезлек, мәйданнар, сәясәт.



- Милләтпәрвәр шәхес, артык тыйнак, миһербанлы зат булды, ул бервакытта да үлем турында уйламады, һәр туган көнгә өмет белән карады, шәхси борчуларын онытып, милләтебез мәнфәгатен кайгыртуны изге максат итеп куйды.
- Кеше язмышы, ил, тел, дин язмышы дип янды.

- “Без: Ул юк инде, ул китте, - дип ах-ух килеп яшәргә тиеш түгел, ә халкыбызның менә нинди матур да, батыр да кызы бар, аның җырлары, сандугачлар сайравына тиң тавышы бар дияргә тиешбез.”

## “Тургайның яшен сорама...”

***Марсель Гали ,“Шәһри Казан”газетасы, 15 май, 1992 ел***

**Шушы көннәрдә Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрында Татарстанның халык артисткасы Вафирә Гыйззәтуллинаның бенифисы узды.**

Куллары пар канат... Әле оча, әле йөзә, моңнары дулкынынннан сихерләнеп, үз хыялы белән тотынышып әйлән-бәйлән бии – пар канатлы, солтанатлы Вафирә ханым Гыйззәтуллина.

Сәхнәдә – чәчәкләр, чәчәкләр ... Ак, кызыл, ал дулкыннардан торган диңгез. Бу чәчәкләрнең нәзберек таҗларына сак кына кагылып тәкыя үрсәң, Вафирә ханымның гомерендә ул иң олы, иң мәртәбәле, иң кыйммәтле таҗ булыр иде.

Залга моң агыла. Җыр аша ул яшел күлмәкле яшьлегенә кайта. Күңелләрне әле хәсрәт дәрьясына ташлый, әле күккә менгерә – җыр бетеп алкышлар ләйсәне башлануга сәхнәгә ике яклап кешеләр агыла башлый. Кулларында – кадерле сүзләр язылган бүләкләр, чәчәкләр. Җырчыны олылап килгәннәр – Вафирә ханымның туганнары, якташлары, мәйданнарда, кайнар көрәш көннәрендә, халкыбыз каһарманнарына рух биреп торган самими әбиләргә кадәр сәхнәгә менгәннәр. Җырчыга җылы сүзләрен әйтеп каласылары килә.

Җыр арасында тагын котлаулар – җөмһүриятебезнең мәртәбәле шәхесләре – сәясәтчеләр, шагыйрьләр сәхнәгә агыла. Чәчәкләр, чәчәкләр ... Вафирә ханым чәчәкләр болытын кочагына сыйдыра алмый. Иксез-чиксез илнең күпме юлларын узган. Балтыйк буеның Татар күленнән башлап, кояш чыгышы янындагы Татар бугазына кадәрге араны колачлаган шәхес бит ул, югыйсә. Американың небоскреблар урманы эченнән, шаулы Манхэттен урамыннан җырлап узган кыз бит ул Вафирә. Испан кайнарлыгы белән җырлап, Куба негрларын шашындырып биеткән кыз булыр ул Кама буенда туган Камай кызы Вафирә.

Сәхнәдә – чәчәкләр. Җырчының үткән иҗатына борылып карап, киләчәккә күз атуы – кичәнең асыл мәгънәсе булды. Вафирә Гыйззәтуллина беренче тапкыр чыккандагыча саф тавыш белән яшәп, бөтен җанын салып җырлады – әйтерсең лә соңгы тапкыр сәхнәгә чыга. Шулай булырга тиеш. Рәссам соңгы картинам дип бөтен көчен салып ясаса, шагыйрь соңгы шигырем дип бәгыреннән сүзләр алса, аһәңсаз (композитор) соңгы көем дип җан авазы белән язса ... Тәңре мондый иҗат аһеленә тагын да бетмәс илһам иңдерә.

Сәхнәдә – чәчәкләр. Халкыбызның моңлы баласын, талантлы кызын чәчәкле алкышларга күмгән бу кичәнең кайтавазы хәтерләрне кабат-кабат яшәртер әле.



## “Чәчәкләр бәйләме”

***Кояш Тимбикова,1996 ел.***

Быелгы яз әдәби-мәдәни-сәнгати бәйрәмнәргә ифрат бай булды. Хәер, язы гына да түгел, елның үзен үк мөхтәрәм әдибебез Гомәр ага Бәшировның зур тантанасыннан башлаган идек. Шуннан китте дә китте. Әле шагыйрьләр үз иҗатына багышланган кичәгә

чакыралар, әле тарихи шәхесләрнең юбилей тантаналары гөрләп үтә. Ул даһи Тукайның тууына 110 ел тулу выкыйгасын әйткән дә юк - айлар буена сузылды. Чөнки Тукай, үз бәйрәменә ияреп, аның исемендәге бүләккә ия булучылар шатлыгын тартып чыгарды. Татарстанга сөекле җырчыбыз Фәридә ханым Кудашева килде, аның белән очрашулар безне Сәйдәш музеена чакырды. Сәйдәш “сүз алдымы”, анда инде кадерле җырчыларыбызның кайсы гына битараф калыр икән?! Шул очрашуда ук безне иң нәфис тавышлы “сандугачыбыз”, соклангыч талант иясе Вафирә ханым Гыйззәтуллина үзенең бенифисына чакырды.

Һәм ул яңа шатлыклы кичә килеп тә җитте. Казан үзәгендәге Камал театры, ишекләрен киң ачып, татар җырын яратучыларны, алай гына да түгел, татар җырын бик ихластан бирелеп сәнгатьчә башкаручы артистканы тансыклаучыларны каршы алды. Вафирә ханым тантанасын зурларга Казан,Мәскәү, Чаллы кунаклары, туган ягы кешеләре күп килгән иде. Залны шыгрым тутырган җыр сөючеләр пәрдә күтәрелүен, аның түрендә гармунчы белән җырчының моң сузуын көтеп калдылар. Әмма кичә бөтенләй башкача башланып китте. Зур белемле, җыр сәнгатенең “маен чыгарып” иҗат итүче Вафирә ханым кичә барышын өр-яңа көйгә салган булып чыкты. Сәхнә түрендә оркестр. Татарстан радио һәм телевидение оешмаларының берләштерелгән оркестрын күренекле музыкант Рөстәм Үтәй җитәкли. Беренче “сүз”аларга бирелде. Тамаша залы гына түгел, бар дөнья Сәйдәш музыкасы сихеренә күмелде кебек. Чыдасаң-чыда, чыдамасаң-ела. Агыла да моң агыла. Һәм ... залдагыларның кайберләре елый да елый ...

Озак көттермичә, Вафирә – сандугач үзе дә талга кунды. Күз алдыгызга китерегез: биек-биек баскыч, шуннан, аның иң югарыдагы басмаларыннан ап-ак канатлы кошчыгыбыз сайрап оча. Вафирә бу, Вафирә Гыйззәтуллина!

... Нәрсә булды күзгә,
Нәрсә булды безгә,
Килде җиргә ике яз!

Язгы җырга башка җырлар кушылды. Бер җыр - мең чәчәк! Бер җыр – тагын мең чәчәк! Ирексездән сорау туа: каян үсеп өлгергән бу чәчәкләр? Бөтен Җир шары бары аңа гына багышлап кочак-кочак чәчәкләр үстергән диярсең, валлаһи! Залда да чәчәк бәйләмнәре, сәхнәне дә чәчәк бәйләмнәре тутырды.

Чәчәк бәйләмнәренең , ягъни җырчыны котлаучыларның иге-чиге юк иде кебек. Очраклы кеше юк монда. Бирегә җыелганнарның һәммәсе инде дистә еллар буе җырчы Вафирә тавышына сокланып яшәүчеләр, аны зурлаучылар, аны үз язмышларының бер өлеше итеп тоючылар.

Шул фикергәябыштырып, тагын бер сүзне үрчетеп китәргә мөмкин. Әйтик,бенефис хәтле бенефиста, 30 ел дәверендә татар сәхнәсенә хезмәт күрсәткән адәм баласына ни өчен зур-зур бүләкләр тапшырылмаган? Бу сорау минем үз башыма кереп тә чыкмаган булыр иде. Чөнки без, соңгы җитмеш ел буе тәрбияләнгән “совет” балалары, андый нәрсәләргә, гомумән, өйрәнмәгән. Вафирәнең искиткеч уңышлы концертыннан соң, аның белән күрше-күлән миңа сорау биреп аптыратты:

- Ә кайда ат?

- Ник аңа машина бирмәделәр?

Мин чарасыз идем. Чөнки, чыннан да, соңгы елларда, гомер буе күрелмәгәнчә, юк кына чарада да әле бирәүгә, әле  икенчесенә ат хәтле ат, машина хәтле машина бирәләр. Хәтта ышануы да кыен. Ничек инде ул? Кешеләр эшләп-

эшләп тә биш-алты ай буе хезмәт хакы ала алмыйлар. “Ник?”- дисәң, “Акча юк”, - диләр. Ә сәхнәләрдән ачкычы-фәләне белән машина тоттырып төшерәләр.

Сүз башым матурлык, җыр, сәнгать, ярату, аңлашу иде ләбаса! Без бит Вафирәне нәкъ менә машинасыз, татар халкының үзе кебек үк яклаучысыз, бары тик үз көченә генә генә таянып яшәүче җырчы булганы өчен дә яратабыз. Кичәдә Вафирәнең кызы Камилә, туганы Рауза җырлады – тагын ни кирәк?!

Мәгълүм булсын ки, әлеге кичә артистканың сәхнәдә 30 еллык иҗатына багышланган иде. Димәк ки, яз җәйгә алмашыначак. Җәйләүләрнең үз яме, яшеллеге, татлы җимешләре бар. Вафирә Гыйззәтуллина иҗатындагы бу күчешкә яңа җиңүләре белән киләә: ул җырлау осталыгына ялгап үзе дә көйләр чыгару сәләтен чарлап карамакчы... Хәер, нииндидер шик-шөбһәләр яки сынамышлар белән сүз озайтуның, бәлки, кирәге дә юктыр инде.Ул - бу өлкәдәге сынауны әлеге бенефисында ук узды. Үз көйләренә һәм үз сүзләренә язган җырларны башкаргач, Вафирәгә чәчәк бәйләмнәренең тагын да күркәмрәкләре,күләмлеләре яуды. Чәчәкләрне үз куллары белән аңа ирештерергә өмете өзелгәннәр нәркисләрне, бакырганнарны һәм дә рауза гөлләрен сәхнәгә турыдан-туры ташларга тотындылар. Бу хәл әлегәчә татар сәхнәсендә күрелмәгән хәл иде.Мондый бенефислар турында миңа Фатыйма Ильская гына сөйләгәне бар иде.

Быелгы яз рухы дөньябызда зур-зур бәйрәмнәргә китерде. Мин сезгә шуларның берсе турында гына сөйләп бирдем. Бу – Вафирә бәйрәме, Вафирә Гыйззәтуллина тантанасы, сәнгати югарылыктагы җырыбыз җиңүе! Шул кичәдә катнаша алмаганнарыбыз да кул чабыйк, баш иик бу затка, киләчәгенә иҗади уңышлар телик!

Вафирә безгә, Татарстан язучыларына, аерым кадерле. Чөнки ул безнең иң мөхтәрәм шагыйрьләребез Сибгат Хәким, Саҗидә Сөләйманова, Равил Фәйзуллин, Рәдиф Гаташ белән дә, гомумән, әдәбиятыбыз тормышы-көнкүреше белән дә иң якын элемтәдә тора, ягъни мәсәлән, безгә үз кеше ул! Чәчәкләр бәйләмебезнең иң күркәме – аңа, аның бенефисына!

## “Ай былбылым…”

***Абдулла Сәләхетдинов, “Ялкын”журналы.***



Чикаго шәһәрендәге зур концерт залларының берсендә алма төшәрлек тә урын калмаган. Ике меңнән артык кеше җыелды. Симфоник джаз-оркестр да уйный башлады. Аңа яшь җырчы кызның көмештәй саф тавышы кушылды.

*Ай былбылым, вай былбылым,*
*Агыйделнең камышы...*

Гади җыр, гади көй, ә күңелләргә әллә ниләр сала!

Әйтерсең, күз алдында елга дулкыннары уйный, шул дулкыннар өстенә күктән йолдызлар сибелә, һәм, җиргә төшеп, энҗеләр шикелле җемелди...

Дәрья буеның зифа камышлары шаулый, тугайларында яшел тал-тирәкләр тирбәлә...

Елга буенда таң сызыла. Кояшның беренче нурлары зәңгәр офыкны алтынлый, камышларны аксыл төскә кертә, тирәкләрдәге сандугачларны дәртләндерә. Һәм ул сайрар кошлар, җилкенеп-җилкенеп, матур көй сузалар.

Җырчы кыз, гүя, аларны күреп тора, моңнарын ишетә һәм үзе дә шуларга кушылып китмичә түзә алмый.

*Таң алдыннан чут-чут килә*
*Сандугачлар тавышы...*

Җырчы кыз үзе дә Татарстан былбылы шикелле. Әйтерсең, җырны канат итеп ераклардан очып килгән дә, Америка халкына Идел буйларының матурлыгын сурәтли, шул гүзәл якларны яратуын җыры белән аңлата. Дәртләнеп җырлый ул. Ә джаз-оркестрда уйнаучы негрлар, аның хисләрен аңлап, чын күңелдән елмаялар. Җырчы кызның бәхетенә сөенәләр. Якты җыр, кояшлы җыр зал буйлап агыла.



*Ай былбылым, вай былбылым,*
*Агыйделдә таң ата...*

Бу җырны Вафирә Гыйззәтуллина җырлый.

Аны бу якларга туган ягының тыйнак һәм дәртле җырлары китерде. Ул үзе бу якларга, татар халкының сәламе итеп, шул җырларны алып килде.

Җырны – җырчыдан, җырчыны – җырдан алып булмый. Болар икесе бер бөтен. Ләкин аларны туган илдән, туган җирдән дә аера алмыйсың. Татар былбылы Вафирә Чикагодагы концерт залында өздереп җырлый икән – димәк, аның туган иле җырга бай, үскән җире моңга бай.

Вафирә Гыйззәтуллинаны сәнгать күгенә күтәргән талмас канатлар – халык җырлары. Сабый чактан гашыйк ул аларга. Туган яклары да җыр кебек матур. Акчарлаклы Кама буйлары... Шәмдәй төз басып торган наратлы урманнар... Ул җиләкле аланнар, ул бөрлегәнле әрәмәлекләр, ул игенле кырлар дисеңме – барысы да бар анда. Алабуга тирәләренең матурлыгы тикмәгә генә Шишкин рәсемнәренә күчмәгән бит! Шундый шигърияtle якларда туып-үскән кыз Вафирә. Әкияттәге кебек, берсеннән-берсе матур, уңган сигез туган үскән Камай авылында. Җыр канатлары шул сигезәүнең берсен – Вафирәне авылдан күтәреп алып киткән дә... Башта район буйлап йөрткән... Аннары республика киңлекләренә чыгарган... Бөтен илне гиздергән, дөнья буйлап йөртергә керешкән.

Җырчы булырга хыялланды дип тә әйтеп булмый аны. Хыялланмады дисәң дә дөрес түгел. Күңел почмагында яшеренеп яткан очкыннар беркөнне дөрләп кабынган да, Вафирәнең җырга таланты барын ачканнар. Кошны – канат, кешене талант күтәрә диләр. Тормыш юллары Гыззәтуллинаны сәнгатькә алып керде.

Туган авылында сигезьеллык мәктәпне тәмамлагач та Алабугадагы культура-агарту училищесында укыды Вафирә. Китапханәче булырга иде исәбе. Ә карасаң, күңел кошы клуб ягына җилпенә икән. Камай авылында клуб мөдире булып китте ул. Җыр сөюче егетләр һәм кызлар һәр колхозда бар, шундыйлардан хор оештырып җибәрде. Концерт әзерләделәр...

- “Су юлы”. Камай авылы клубы каршындагы үзешчән хор башкара. Башлап җырлаучыбыз – Вафирә Гыйззәтуллина...

Авыл сәхнәсендә беренче тапкыр яңгыраган бу исем көннән-көн ешрак ишетелә башлый.

1964 нче елның көзендә шул “Су юлы” аны Казанга алып килде. Хорда башлап җырлаучы Вафирә Гыйззәтуллинаны Республика халык иҗаты йортына чакыртып алдылар.

- Әйдәгез, республика смотрына әзерләнеп карыйк, сеңелем!..

Әзерләнде Вафирә. Репетицияләр белән мавыгып, көннәрнең үткәнен дә сизмәде. Бер айдан республика смотрында бик әйбәт җырлады. Халык талантларының Бөтенроссия смотрына – Мәскәүгә җибәрделәр аны. Кремльдәге съездлар Сараенда татар җыры яңгырады:

*Яз айлары, яз айлары*
*Яшелләтә кырларны.*
*Яз айлары хәтерләтә*
*Онытылган җырларны.*

Хөснул Вәлиуллинның “Яз айлары” дигән шул җыры белән уңышка иреште җырчы кыз. Мәскәүдән канатланып кайтты ул. Үзешчән сәнгать коллективларының Бөтенроссия конкурсы лауреаты булып кайтты.

Менә шунда инде күңел “җыр!” дип талпынды, ашкынды. Музыка училищесына керде Вафирә. Дәртләнеп җырлаган шикелле үк, ашкынып укыды да ул: беренче курсны ярты елда тәмамлады. Дүрт еллык программаны ике ел ярымда төгәлләп чыкты. Музыкаль белем баскычлары аны консерваториягә китерде...

Вафирә Гыйззәтуллина үзе искә төшерә:

- Өченче курста укыган чакта Австриядә булып кайтырга туры килде. Казанда “Чулпан” дигән бию ансамбле бар иде, шуның белән бардык. Бию янына җыр да кирәк дип, Ренат Ибраһимов белән мине чакырдылар.Җилкәгә нинди авыр йөк алуымны Австриягә җиткәч кенә аңладым. Бу илнең халкы музыка сәнгатен үлеп ярата. Аның музыкантлары, композиторлары – гигантлар. Моцарт, Штраус, Шуберт, Бетховен!.. Менә кемнәр белән горурлана Австрия халкы. Боларның исемнәрен генә телгә алсаң да күңелеңдә музыка өермәләре, давыллары куба. Ә безнең нәрсәбез бар?..

“Мескенләнмик, - диде миңа йөрәк авазы. – Халыктан да зуррак композитор булмас!”

Ренат “Әдрән диңгез”не җырлады. Салих абый Сәйдәшнең көен Вена алкышлады. Мин татар халык җырларын – “Сибелә чәчәк”, “Көймә килә”не җырладым. Веналылар бик ошатты. Карасаң, безнең дә дөньяга чыгарырлык хәзинәбез бәләкәй түгел икән!...

Яшьләрнең Вена фестиваленнән “Чулпан” ансамбле алтын медаль алып кайтты. Ә Ренат белән Вафирә – Грамоталар.

1973 нче ел. Воронеж шәһәрендә халык җырларын башкаручыларның Бөтенсоюз конкурсы. Аңа илнең төрле якларыннан 74 җырчы килде. Берничә көн буена шәһәрнең иң яхшы концерт залында төрле төрле телләрдә җырлар яңгырады.

Сәхнәдә Вафирә Гыйззәтуллина. Әнә ул башын әз генә кырынрак салган да, мөлаем көлемсерәп, “Фазыл чишмәсе”н җырлый. Чишмә челтерәве тынып, алкышлар залны тетрәтеп узгач, яңа җыр башлый. Монысы инде – татар халкы узган тарих юлы кебек кырыс һәм давыллы:

*Кара дагынай урман, караңгы төн,*
*Яхшы атлар кирәк үтәргә...*

Воронеждан “Карурман” кичеп кайта Вафирә, Бөтенсоюз конкурсы лаураты исемен алып кайта.

Шул көннәрдә генә совет яшьләре делегациясе Америкага барырга әзерләнә иде. Шуның сәнгать группасына Дагестан АССРның “Лезгинка” бию ансамбле,

беларус җырчысы, рус акробатлары һәм татар җырчысы Вафирә Гыйззәтуллина кертелә.

Делегация Америка буйлап сәяхәт итә, төрле шәһәрләрдә була. Нью-Йорк, Вашингтон, Чикаго, Лос-Анжелос… Совет иленең егетләре һәм кызлары америкалы яшьтәшләре белән очрашалар. Дискуссияләр, конференцияләр үткәрелә... Җырчы кыз Вафирә аларда актив катнаша. Берничә конференциядә доклад сөйли. Ул болай ди:

- Безнең яшьләр өчен иң мөһиме – ил алдындагы бурычны яхшырак үтәргә омтылыш, минемчә. Америка яшьләренә исә бу фикер тиз генә барып җитми. Чөнки анда кеше иң элек үзен кайгырта...

Америкада 18 көн йөрдек. Унлап коцерт булды. Чикаго аеруча хәтердә калды...

Рузвельт исемендәге университетның симфоник джаз оркестры дан тота икән. Ул оркестрның уенчылары барысы да негрлар. Безнең татар җырларын бик ошата алар.

- Безгә берничә җырыгызның нотасын бирегезче, - дип мөрәҗәгать итә Вафирәгә оркестр җитәкчесе. – Без аны джаз-оркестр өчен эшләр идек.

- “Көймә килә” белән “Ай былбылым” көйләренең ноталарын бүләк иттем аңа, - ди Вафирә. – Өч сәгатьтән аларны оркестр өчен эшләп китерделәр. Шул джаз-оркестр белән Чикагода өч концертта җырладым...

Җыр канатында илләр гизеп кайткан Вафирә Гыйззәтуллина – хәзер Муса Җәлил исемендәге татар дәүләт опера һәм балет театрында солистка.

Тиздән без аны “Түләк белән Сусылу” операсында Сусылу итеп күрербез...

“Башмагым” музыкаль комедиясендә Сәрвәр булып сәхнәгә чыгар ул...

Римский-Корсаковның “Патша кәләше” операсында Марфа да – Вафирә Гыйззәтуллина.

Жорж Бизеның “Кармен” ында Микаэла да – Вафирә Гыйззәтуллина.

“Алтынчәчтә” – Алтынчәч ул.

Һәм тагын Вафирә апагызны сез концертларда, телевидение тапшыруларында күрерсез, укучы дуслар. Ул балалар өчен язылган җырларны бик теләп һәм матур итеп башкара. Без аңа – Туган ягыбызның җырчы былбылына – зур уңышлар телик.

Җыр канатлары талмасын аның!

**Газетага бирелгән интервьюдан өзек, 2000 ел.**

**Вафирә Гыйззәтуллина, Татарстанның һәм Каракалпакстанның халык җырчысы:**

- XX гасырны начар булды дип әйтә алмыйм, чөнки мин – шушы гасыр кешесе: зур биеклеккә күтәрелдем, кешеләргә, халкыма матурлык өләштем. Һәрвакыт чисталыкка, иманга өндәдем, тәүфыйкка чакырдым.

Әлбәттә, югалтулар да күп. Әмма мин узып баручы гасырга рәнҗешле түгел. Әгәр дә XXI гасырның, һич югы, яртысы шундый булса, телебез дә, иманыбыз да сакланыр, дәүләтебез дә үсәр.

Яшьләр мәсьәләсенә килгәндә, татар яшьләре бергә берләшсеннәр иде. Замана, киләчәк сезнең кулда булачак. Безне дә онытмыйча, тәҗрибә уртаклашып яшәсеннәр иде.

## “Тавышым – үзе байлык...”

***Гөлназ Шәйхи, “Акчарлак” газетасы, 2001 ел, гыйнвар.***

*Татар җыры, аның үткәне, бүгенгесе турында фикерләрен белү максатыннан халкыбызның яраткан җырчысы, Татарстанның һәм Каракалпакстанның халык, Россиянең атказанган артисты Вафирә Гыйззәтуллинага мөрәҗәгать иттем.*

**- Яңа гасырга аяк бастык. Ничек уйлыйсыз, Вафирә ханым, татар эстрадасы өченче меңъеллыкка нинди уңышлар белән керә?**

- Соңгы ун ел эчендә интервьюлар күп бирдем, чыгышлар да күп ясадым. Милләт турында уйласаң, татар халкын яшәтәсең, дөньяны матурлыйсың килсә, бу сорауга битараф калып булмый. Минем фикерем шундый: бүгенге көндә татар эстрадасы юк ул. “Татар җыры – 2000” дип язылган афиша эленеп торды, тик безне, урта буын җырчыларын дип әйтик инде, әлеге концертка чакырган кеше булмады. Югыйсә карт-коры түгелбез бит әле, ни генә дисәләр дә, узган гасырның төп җырчылары идек. Мин үземне 35 ел буе классик сәнгатьне тартып баручы дип саныйм. Оялып әйтмим. Сүзләремне халкым да дөрес аңлар. XXI гасыр мәдәният, сәнгать, әдәбият гасыры булачак дип әйтәләр. Бу чыннан да шулай булсын иде. Ничек кенә булмасын, яңа меңъеллыкка кергәндә, алдымда шундый бер яктылык күрдем. 15 ноябрь көнне Зур концерт залында концертым булды. 35 ел иҗат итү дәверемнең бөтен максаты Рөстәм Яхинны зурлап сәхнәгә менгерү иде. Хыялым, ниһаять, тормышка ашты.

Миңа: “Яхин – синең хоббиең инде ул”, - диделәр. Юк, Рөстәм Яхин – минем бөтен иҗатым. Элек тә әйткәнем бар, тагын кабатлыйм, музыка әсәрләребез Яхин әсәрләре дәрәҗәсенә күтәрелсә, татар халкы үзен милләт буларак саклап калачак.

- Бүгенге җыр сәнгатенең нигезен кемнәр тәшкил итә дип саныйсыз?

- Профессиональ күзлектән караганда, четерекле дә, авыр да, куркыныч та сорау бу. Зәйнәп белән Зөфәр, Алла боерса, беркөн килеп классикага да игътибар итәрләр дип уйлыйм. Габделфәткә дә зур өметләр баглыйм. Газета чыгарам дип,



җыр сәнгатен онытa күрмәсен. Илсур Сафинны үстерергә кирәк. Нуриәхмәт Мөхәммәтҗанның дә тавышы бар. Алсу Хисамиеваның киләчәге өметле. Музыка училищесының татар бүлегендә, консерваториядә дә бар берничә талант. Тәмле әйбер күп булмый ул! Әмма унбишләп башкаручыны бик рәхәтләнеп саный алам. Алда телгә алынган җырчыларны башкалардан өстенрәк куям икән, алар инде Вафирә апаларының йөзенә кызыллык китерергә тиеш түгелләр. Диапазоннары киң. Сәнгатькә баштанаяк чумарга, эзләнергә, Рөстәм Үтәй оркестры белән дә җырларга кирәк.

- Халык җырларның сүзе гел бертөрле дип зарлана.

- Дөрес әйтәләр. Күбесенчә сүзе генә түгел, көе дә юк аларның. Чит ил җырларының көйләрен алалар да шуңа сүз өстиләр. Рус эстрадасы хәзер “старые песни в новом исполнении” дип талпына. Безгә дә элеккеге җырларыбызны барларга кирәк.

Профессионаллар һәм үзешчәннәр язган җырлар бар. Үзешчәннәр язган җырлар начар димим. Алар арасында бик тә матурлары бар. Тыңлыйсың да

канатланып китәсең. Ләкин истә калмыйлар бит. Заһит Хәбибуллинның “Сагыну”ын, Исмай Шәмсетдиновның “Кызарып кояш баткан чакта”сын, Рөстәм Яхинның “Китмә, сандугач”ын онытып кара син?! Ачылып бетмәгән композиторыбыз Мансур Мозаффаров бар әле безнең. Мин әйтеп узган җырчылар, шушы бөек шәхесләребезнең әсәрләрен яңартып, кабат сәхнәгә меңгерерләр дип уйлыйм.

Узешчән композиторларыбыз да язсын. Аларның җырлары да яңгырасын. Ул җырлар акны карадан аеру өчен дә кирәк.

- Сез атап киткән композиторларның юлын дәвам иттерүчеләр бармы бүген?

- XXI гасыр хатын-кызлар гасыры булыр дип фараз итәләр. Коръәндә дә шулай язылган. Луиза Батыр-Болгари, Резеда Ахиярова, Мәсгудә Шәмсетдинова, Луиза Хәйретдиноваларга өметем зур. Ир-ат композиторларны бөтенләй белмим диярлек. Муса Маликовны, әлбәттә, үстерергә кирәк. Тагын да алга китеп карасак, дирижерларыбыз да юк бит безнең. Симфоник оркестрыбызның дирижеры Фоат Мансуровны алмаштырырлык кешене кем атый ала? Талантларны халык арасыннан табарга кирәк. Шул уңайдан фестивальләр уздырыр идем мин. Дөрес, аның өчен акча кирәк. Хәзерге заман җырчылары моны оештыра алыр иде. Мәсәлән, “Микрофонсыз җырчылар” бәйгесе үткәркргә мөмкин. Кем микрофонсыз җырлый ала? Оркестр беләнме, рояль беләнме? Менә кая күренер иде талантлар.

- Вафирә ханым, хәзерге заман җырчыларында акча бар дигән фикер үздырдыгыз.

- Әйе. Дөрестән дә шулай. Ә мин байлык артыннан кумадым. Минем тавышым – үзе байлык. Ходай биргәнгә шөкер итеп яшим.

- Вафирә ханым, инде әңгәмәбезгә нокта куяр алдыннан “Акчарлак” газетасына әйтәсе уй-фикерләрегезне дә беләсебез килә.

- Мин XX гасырда яшәдем. Бөтен теләгем, хыялым җыр сәнгатен яктырта торган газета яки журнал булдыру иде. Җыр – зур байлык. Милләтне ул саклады. Классик җыр сәнгатенең нигезен тәшкил иткән Азат Аббасов, Наҗия Теркулова, Мөнирә Булатова, Җәвәһирә Сәләхова, Рәисә Билаловалар бүгенге көндә исән-сау, Аллага шөкер. Алар белән дә очрашып, укучыларга фикерләрен җиткерсәгез иде.

Мин Кабан күле буенда йөрергә, акчарлакларны күзәтергә яратам. Ике акчарлагым да бар. Алар хәзер мине таныйлар, кулдан ашарга курыкмыйлар. “Акчарлак” та курыкмыйча гел алга омтылсын. Уңышлар аңа!

## “Эзләп тапкан бәхет кадерле...”

*Лилия Галиева, Менделеев шәһәр һәм район мәдәният бүлеге җитәкчесе.*

Һәр чишмәнең үз тавышы бар. Аны бер тапкыр ишетсәң, бүтән беркайчан да онытмыйсың. Җырчы Вафирә Гыйззәтуллинаның тавышы чишмә чылтыравын хәтерләтә.

Вафирә, халык җырыннан алынган диярсең, шундый шигъри атамалы Камай авылында туган. Гыйзәтуллиннар гаиләсендә музыка һәрвакыт мактаулы була. Күрәсең, ул авыр тормыш елларын җиңәргә булышкан. Гаилә башлыгы Мөхәммәтдин абый фронттан яраланып кайта. Авылдашлары аны колхоз рәисе итеп сайлыйлар. Ятим калган балаларны, тол хатыннар күргән элеккеге солдатның йөрәге сыкрый. Мондый минутларда ул кулына гармун ала һәм әкрен генә моңлы көйне сыза башлый. Хатыны Бәдерниса апа аңа кушылып җырлый.

Сугыштан соңгы авыр елларда ике кулга тагын биш кыз һәм бер малай үстәлә. Барлык балалары да әйбәт кешеләр булып үскән һәм илнең төрле шәһәрләренә һәм авылларына таралган.

Үз җырын ахырына кадәр җырлап бетерә алмыйча, Мөхәммәтдин абый дөнья куя. Бәдерниса апа туган йортында, туган авылында кече улы Мансур гаиләсендә яшәп кала.

Гыйззәтуллиннарның бер кызы – Вафирәнең сәнгатькә юлы турыдан һәм җиңелдән булмый. Авылда сигезъеллыкны тәмамлагач, ул Алабуга культура-агарту училищесында укый. Аны тәмамлагач, Камай китапханәсендә эшли, үзешчән сәнгатьтә катнаша. Авылда хор оештыра, үзе шуның солисткасы була. Үзешчән сәнгать смотрларның берсендә аны белгечләр искәреп кала. Һәм кызга җырларга, укырга, профессиональ җырчы булырга тәкъдим итәләр. 2,5 ел эчендә ул Казан музыка училищесын бик яхшыга тәмамлый. Вафирә моның белән генә тукталып калмый, Казан дәүләт консерваториясенә керә. Аны тәгәлләгәч, Татарстанның Г. Тукай исемендәге Дәүләт филармониясендә солистка-вокалистка булып эшли башлый. Зур сәнгатьтә беренче адымнарыннан ук Вафирә Гыйззәтуллина үзе турында эстрадада үзенчәлекле кеше кебек белдерде. Бөтенсоюз һәм Халыкара конкурслар призлары – моңа ачык дәлил. Ул Татарстан һәм Каракалпак республикаларының халык артисткасы исеменә лаек булды. Аның гастроль маршрутлары белән глобус картасы буйлап танышырга кирәк. Чөнки ул – Карпаттан Чукоткага кадәр. Кама ярларыннан килгән җырчыны Германиядә, Австриядә, АКШта кайнар каршыладылар. Ул Кубада Бөтендөнья яшьләр фестивалендә катнашты. Вафирә Гыйззәтуллинаның иҗаты бик халыкчан. Анда фольклор милли традицияләр һәм заманча ритмнар органик үрелгән. Әгәр Вафирәдә милләтчелек аңа саф татар аһәңнәре бирүче халыктан, әтисеннән һәм әнисеннән килгән булса, заманчалыкны тою – аның югары эчке культурасыннан, үзенә таләпчәнлектән, чиктән тыш ихласлыгыннан, тулысынча шушы эшкә бирелгәнлектән. Ул үзе ярты көчкә генә эшли, яртылаш кына яна белми. Сәхнәдә генә түгел, ә бәлки тормышта да аңа күңел сафлыгы, эмоциональ изелүдән котылу хас. Бу – кешегә, яхшылыкка ышану нәтиҗәсе. Аның кызыксыну дөньясы күпкырлы һәм киң. Ләкин анда төп урынны музыка, шигърият һәм сәхнә ала. Вафирә үз алдында барлык иҗат кешеләре өчен уртак максат күрә: кешеләр хисләрен камилләштереп, аларны тәрбияләп, тормышта югары идеалларны раслап, халык тормышын яхшырту.



Соңгы вакытта Вафирә Гыйззәтуллинаның тавышы митингларда, җыелышларда ишетелә. Менә дигән лирик тавышлы бу хатын-кызның сәясәткә килеп керүе бер дә гаҗәп түгел. Чөнки бүген җырлар белән белдереп булмаган сүзләр бар. Җөмһүриятебезнең киләчәге, милләтебезнең язмышы хәл ителгән чакта битарафлык ташын җимерү, халыкны уяту өчен кычкырасы килә. Егерменче гасыр тәгәлләнеп килә: халыклар үзара сугыша, бер-берсен изә, безне билгесезлеккә алып китәләр.

Халыкта тормышка мәхәббәт беркайчан да сүнмәс. Чөнки авыр елларда һәм кыен вакытта кешеләр җырда, күңел кылларын тибрәтерлек моңда юаныч табалар. Ник дисәң, татарлар элек-электән үзләренең күңел яраларын моң белән дәвалыйлар һәм үзләренең яшәүгә сәләтле булуларын фидакарь хезмәтләре, тыйнаклыклары, сусаганны басучы Бөек Моң белән исбатлыйлар. Казан шәһәрендә май ае кичләренең берсендә Вафирә Гыйззәтуллинаның бенефис-кичәсендә бөтенләе белән шушы лейтмотив яңгырады. Тамашачыларның чәчәк бәйләмнәре белән уратып алынган тулы залы тантаналы иде (кешеләр үтү юлларында басып тордылар, баскычларда утырдылар). Вафирә Гыйззәтуллина адресына әйтелгән яхшы сүзләр үзләре турында үзләре ачык сөйли. Бу бәйрәм аныкына гына түгел, ә халык бәйрәменә, җыр бәйрәменә әверелде.

Легендар иҗат яшәгәндә, халык иҗаты исән, милләт яши һәм чәчәк ата.

## Күренекле җырчы истәлегенә

***Татар-Информ***

Шушы көннәрдә Бөтентатар иҗтимагый үзәгенең Чаллы бүлеге Татарстан Республикасы һәм Шәһәр көне уңаеннан ТР Президенты Минтимер Шәймиев, ТР мәдәният министры Илдус Тарханов, Менделеев районы хакимияте башлыгы Рөстәм Гафаров, Татарстан районнары һәм шәһәрләре башлыклары исеменә мөрәҗәгать юллады.

“Татарстан Республикасының дәүләт мөстәкыйльлеге турындагы декларациясе” кабул ителүнең 12 еллыгы уңаеннан күренекле җырчы, җәмагать эшлеклесе, фаҗигале рәвештә һәлак булган Вафирә Гыйззәтуллина исеме хәтердә яңара”, - диелгән мөрәҗәгатьтә.

Вафирә ханым Менделеев районында туып-үсә. Гомеренең күп елларын Казан шәһәрендә үткәрә. Монда ул үз халкының мөстәкыйльлеге өчен көрәшә, татар мәдәниятенә үзеннән зур өлеш кертә. Аның җырлары Татарстанда гына түгел, чит төбәкләрдә дә үз тыңлаучыларын таба.

Моны истә тотып, Бөтентатар иҗтимагый үзәгенең Чаллы бүләге әгъзалары Казандагы, Менделеевск каласындагы, Татарстанның башка районнарындагы мәдәният объектларына Вафирә Гыйззәтуллина исемен бирүне сорап мөрәҗәгать итә.

## “Камай сандугачы...”

***М. Григорьева,”Менделеев яңалыклары”, 17 сентябрь, 2004 ел.***

**Моннан 3 ел элек, 16 сентябрьдә, зур талант иясе, җырчы, Россиянең атказанган, Татарстанның һәм Каракалпакстанның халык артисты Вафирә Гыйззәтуллинаның гомере вакытсыз өзелде. Шунлыктан бу көн якташыбызны искә алу көне буларак билгеләп үтелә.**

Шушы уңайдан Камай мәктәбендә күләмле кичә оештырылды. Анда мәктәпнең укучылар коллективы, җырчының якыннары һәм авылдашлары, ветераннар, әлеге чарага килгән кунаклар катнашты.

Чара барышында мәктәп укучылары мәрхүм җырчының репертуарыннан сайлап алынган моңлы һәм дәртле җырларны башкардылар. Аның рухын искә алып, Г. Фәйзуллина һәм башка өлкән яшьтәгеләр тарафыннан дога кылынды.

Хакимият башлыгы урынбасары Л. Галиева үз чыгышында аның татар халкының сөекле җырчысы булуын ассызыклады.

“Камай” фермер хуҗалыгы рәисе Әлфия Хәйриева, педагогик хезмәт ветераннары Наилә Миңнәхмәтова, Гайшә Сәгъдиева, аны бик яхшы белгән һәм

еш аралашкан сабакташы Илгизәр Тимергалиева хатирәләре белән уртаклаштылар.

Мәктәп бинасында урнашкан авыл китапханәсендә шушы җирдән күтәрелгән олуг шәхесләр Вафирә Гыйззәтуллина, Дифкать Сираев, үзешчән артистлар Юзикеевлар, танылган җырчы Рәмзия Зиннәтуллина һәм башкалар турында материаллар туплана. Әлеге учреждениягә килгән кешеләргә, теләкләре булса, алар белән танышу өчен мөмкинлек бирелә. Мәктәп коллективы авылның зыялылары, күренекле кешеләре турындагы документлар һәм башка материаллар туплау эшен башлап җибәргән. Бу тарихи истәлекләр оештырылачак музей бүлмәсенә нигез салучы экспонатлар булачак. Анда Вафирә Гыйззәтуллина турындагы материаллар тупланмасы да лаеклы урын алачак. Искә алу кичәсендәге чыгышлар вакытында шундый фикер яңгырады. Әлеге чара мәрхүмә Вафирә Гыйззәтуллинаның авыл зиратындагы каберендә булу, анда чәчәкләр салу һәм изге догалар уку белән тәмамланды.

Вафирә ханым ихластан халык җырчысы гына түгел, гомеренең соңгы көннәренә кадәр аның язмышы өчен көрәшүче дә булды. Шуның белән ул канәгатьләнү алды һәм үзен бәхетле санады. Инде фани дөньядан киткән булса да, ул һаман да үзенең җырлары белән безнең арабызда, аның җырлары үлемсез. Вафирә Гыйззәтуллинаның исеме һәм моңы һичкайчан хәтеребездән китмәс. Җырларын ишеткән саен, без аны сагынып һәм хөрмәтләп искә алабыз. Аның якты истәлеге күңелләрдә мәңге сакланыр.

## **“Үзе чая, үзе сөйкемле...”**

***Зөһрә Сәхәбиева, Татарстанның халык артисткасы ,“Tatar ile” гасетасы, 2006 ел.***

***Казан дәүләт консерваториясенең әзерлек бүлегенә укырга кергән елларымда Вафирә өченче курста укый торган һәм сабакташлары арасында инде популярлашып килә торган җырчы иде.***

Алай гына да түгел, татар шагыйрьләре, композиторлары, аңа өметләр баглап, җырларын, яңа әсәрләрен дә тәкъдим итәләр, төрле кичәләргә җырларга чакыралар. Ни өчендер, иң беренче тыңлавымда ук минем күңелемә ул нәкъ менә бөек шагыйребез Һади Такташның “Алсу” шигыренә җырлана торган җыры белән бик матур тәэсир итте. Мин бу җырны беренче мәртәбә Вафирә башкаруында ишеттем. Сәхнәдә чибәр, матур тавышлы кыз Вафирә нәкъ менә үзе турында җырлый кебек тоелды миңа. Ул көнне Вафирә Казан дәүләт консерваториясенең 2 нче катында урнашкан залның сәхнәсендә вокал дәресләре буенча чираттагы имтиханын тота (җырлый) иде. Залда вокал дәресләрен укыта торган күренекле профессорлар (алда утырганнар) һәм без – студентлар – тыңлап утыручылар.



*Алсу килә, уйный-көлә*
*Үзе чая, үзе сөйкемле.*
*Үзе усал, үзе болай бер дә*
*Усал түгел кебек шикелле...*

Сәхнәдә татар кызларының бөтен матурлыгын, сөйкемлелеген, чаялыгын, батырлыгын үзенә җыйган зифа буйлы яшь-яшь ханым. Ә тавышы бик матур, иркен агыла, бернинди аврлыксыз җырлый, инде аңа алга таба укып торасы юк кебек, тавышы белән бик җиңел

идарә итә. Ә жырындагы Алсу образын, аның гүзәллеген ихлас күңеленнән жырлап тасвирлый. Такташның “Алсу”ы һәм Вафирә арасында күп охшашлык бар кебек тоела. Әйтерсең лә Такташ бу шигырен язганда Вафирәнең дә чибәрлеген, холкын күздә тотып язган.

Әйе, Вафирә татар халкының гүзәл, сөйкемле, чая, талантлы, кыю кызы иде (“иде” дигән сүзне язуы да авыр). Без аның белән берничә ел бер тулай торакта яшәдек. Үз телебездә сөйләшергә ярамаган елларда миңа аның чатнатып татарча сөйләшүе дә бик ошый иде. Ул вакытларда консерваториянең төрле курсларында жырчы булыр өчен укыган безнең буын студентлары – күбебез авыл балалары идек. Моның өчен бөек шәхес – ул вакыттагы ректор, танылган композитор Нәжип Гаяз улы Жиһановка рәхмәтлебез. Нәкъ менә ул, шәхсән үзе, авыл жирләрендә туып үскән милли талантларга – татар яшьләренә зур игътибар күрсәтә иде, укытып чыгарырга, белемле, мәгърифәтле кешеләр итәргә тырышты ул.Без укыган заманнарның үз үзенчәлекләре бар иде: авылдан килгән татар кызлары, егетләре үз телләрендә сөйләшергә оялып, русча сөйләшергә тырышалар. Бу жәһәттән дә Нәжип абыйны (без аны якын күреп, авылча, Нәжип абый, дип йөри идек) искә төшермичә булмый, әгәр татар балаларының үзе белән вата-жимерә русча сөйләшергә тырышуларын сизсә : “Үз туган телебездә сөйләш минем белән”, - дип төзәтеп куя иде (шәхсән минем үзем белән шулай булганы бар). Ул елларда укыган татар кызларының татарча белгәнлекләрен мин шактый озак еллар узгач кына белеп шаккаттым. “На всякий случай” русча сөйләшә торган булганнар икән. Ә Вафирә татарча сөйләшергә курыкмый, оялмый, татарча уйный-көлә, шаярта, жырлый. Шуңа күрәдер дә мин аңарга тартылдым.

Медицина буенча махсус белемем булганга күрә, тулай торакта яшәгән күп кенә студентларга медицина ярдәме күрсәтергә туры килә иде миңа. Бу хакта Вафирә дә еш кына мөрәжәгать иткәләде. Ул яшәгән икеурынлы бүлмәгә кергәч, Вафирәнең жыйнак, чиста, пөхтә яшәвенә игътибар итмичә мөмкин түгел. Ул инде кияүдә, бәләкәч кызы – бик матур курчак кебек Камиләсе бар иде.

Укып чыгып шактый еллар эшләгәч, безгә бер йорттан фатир бирделәр. Ирем Хәйдәр, улым һәм мин беренче подъездда, Вафирә үзенең гаиләсе белән икенче подъездда яшәде. Йөрешеп яшәдек, безнең ул вакытта бәләкәй улыбызны бик ярата иде ул, аның теле ачыла башлаган чакларда безгә, аны сөйләштереп кызык табу өчен, махсус керә иде.

Гомумән, Вафирә һәрнәрсәдән кызык таба, һәрвакыт ачык йөзле, шат күңелле, оптимист булды, көлкеле, шул ук вакытта зыялы мәзәкләр сөйләргә ярата, тирә-юнендәге бөтен кешене “авызына каратып” тота белә иде. Хәйдәр, мин һәм Вафирә бергә очрашкан чакларыбызда ижат, сәнгать турында да сөйләшә, үз фикерләребез белән уртаклаша идек. Бер-беребезнең концертларын калдырмаска тырыштык без.

Милли азатлык көрәше башланган елларда да концерт-митингларда бергә жырлап йөрдек. Ул вакытта халык митингларга йөрергә күнекмәгән, шуңа күрә концерт-митинг булачак дип, безнең фамилияләребезн язып афишалар эләләр иде. Вафирәнең милли сәясәттә кыю көрәшче булуы турында үзенә бер зур күләмле әсәрләр ижат ителер әле. Чөнки Вафирә тормышын, ижатын бәйсезлегебез өчен көрәшкә багышлаган ул елларда күп кенә күренекле шәхесләребез посып яшәделәр, ә соңыннан бик “житди милләтпәрвәр” булып киттеләр.

Жырчы буларак бик матур тембрлы, йомшак лирик сопрано тавышка ия һәм йөрәгендә милләтенең моңы, гаме яткан зур жырчы ул Вафирә. Аның музыкаль

белеме бик тирән: башта Алабуга мәдәни-агарту училищесын, аннан Казан музыка училищесын һәм Казан дәүләт консерваториясенең вокал факультетын тәмамлады. Рус һәм башка телләрдә җырлап, Россиянең төрле театрларында, филармонияләрендә дә эшли алган булыр иде ул. Әмма Вафирәдә ватанпәрвәрлек хисе зур, йөрәге тумыштан килгән чын татар моңы белән тибә иде. Һәм ул үзен туган халкына хезмәт итүгә багышлады.

Профессиональ җырчы булырга омтылган яшьләребез, Вафирәнең магнитофон тасмаларында сакланып калган язмаларын тыңлап, үзләре өчен бик күп файда ала алалар. Ә татар халкына, безгә – аны яраткан, хөрмәт иткән коллегаларына, дусларына, балаларына аның безнең арабызда булмавын аңлавы авыр, бик авыр. Бу тормышка, җәмгыятькә бүген дә Вафирә җитми...

## “Аҗагандай сызылып үткән гомер.”

*“Мәдәни җомга”, 13 октябрь, 2006 ел*

**Редакциябезгә килгән түбәндәге ике хат барчабызны да сискәндереп җибәрде. Гомере фаҗигале төстә өзелгән яраткан җырчыбыз, Татарстанның халык, Русиянең атказанган артисты Вафирә Гыйззәтуллинаны сагынып, күз яшьләре аша язылган хатлар иде ул. Берсе – Вафирә ханымның бертуган сеңлесе Рабига Гыйззәтуллинадан, икенчесе – танылган җырчыбыз белән озак еллар бер бригадада концертлар куеп йөргән җырчы Зәбир Җаббаровтан. Быел, февраль аенда, Вафирә ханымга 60 яшь тулган булыр иде. Ләкин... шушы елның 16 сентябрендә сөекле җырчыбызны югалтканга биш ел тулды.**

## “Апам хатирәсе...”

***Рабига ГЫЙЗЗӘТУЛЛИНА***

Хөрмәтле “Мәдәни җомга” гәзите редакциясе! Сезгә Чаллы шәһәрендә яшәп һәм иҗат итеп ятучы Рабига Гыйззәтуллина яза. Мин сезнең гәзитне һәр елны, чыга башлаганнан бирле алып, аны бер хәрефен дә калдырмыйча укып барам, апам Вафирә дә бик ярата иде гәзитегезне.

Исән булса, быел февральдә сөекле апам Вафирә Гыйззәтуллинага 60 яшь тулган булыр иде. Иде... Иде... Юбилей үткәрәсе урында, истәлекләр язу белән генә чикләнеп калырга туры килә шул...

2001 елның 25 апрель көне. Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры бинасында апамның соңгы бенефисы. Саубуллашу кичәсе булды ул. Кичә беткәннән соң, автобуска төялеп килгән авылдашларны озатканда үрсәләнеп елады апам. Алар бит минем авылыма кайталар, әнәй янына (әнәйнең каберенә диюе) кайталар дип өзгәләнде апам. Бөтен туганнарны берьюлы бергә җыя торган бердәнбер сәбәп иде апамның юбилее. Икенче көнне шундый кояшлы, матур көн иде. Вафирә апа мине җибәрмәде.”Син кал әле, Тукай бәйрәменә барабыз, - диде. Ирек мәйданына трамвайда утырып бардык. Апамның өстендә шундый да матур пиджәк һәм юбка. Трамвайга килеп керүгә, бөтен халык аңа карады. “Вафирә, нигә машинага утырып бармыйсың?” – дип арттан сүз каттылар. “Утырып бкрсам итәгем бөгәрләнә. Тукай бәйрәменә матур барасым килә”, - диде ул көлеп.

Ул җәйне апам 6-7 тапкыр безгә, Чаллыга килде, дачабызда яшәдек.Шунда бер көн аеруча исемдә калды. Ул көнне мин аның кызы Камилә белән – беренче катта, ә апа оныгы Камил белән икенче катта йокларга яттык. Йокы килми, без сөйләшәбез, көлешәбез, кинәт өй эче яктырып киткәндәй булды, апа икенче

каттан йөгереп төште дә: “Менегез әле монда, аҗаган, аҗаган күрдем!” – дияргә тотынды. Икенче катның тәрәзәләреннән “Ижминводы” курортының утлары күренеп тора безгә, шул булгандыр дип юатам апаны. Юк, юк, аҗаган булды, ди. “Нәрсәгә икән ул?” – дип бик аптырады. Минем телевизордан “язгы аҗаган” спектаклен күргәнем бар, хәтерлим, анда аны үлемгә юрадылар. “И Ходаем, балаларым, мин дә үләрмен микәнни?” – диде дә, Вафирә апам төренеп ятты. Без ул төнне йокламыйча чыктык. Апам бу турыда берничә тапкыр искә төшерде, күрешкән саен сөйләде. Шушы сүзләр ничә ел инде җаныма тынычлык бирми.

2001 елның 14 сентябре, Камилнең туган көне иде. “Син гипста булгач, килә алмыйсың инде”, - диде апа, телефоннан шалтыратып (мин, аягымны сындырып, гипста ята идем). Иртәгә авылга кайтачагы, җырчы Илсур Сафинның яңа машина белән кайтарачагы хакында әйтте. “бу юлы әллә нишләп бик куркам, юлда исән-сау кайтырга язсын инде”, - диде соңыннан. “Рабига җаным, сине авылга алып кайтып, син әнәйне караган кебек карыйсым килә сине”, - диде өзгәләнеп. “Аяк төзәлер, башка кайгы күрергә язмасын”, - дидем дә, саубуллаштык.

Бу безнең соңгы сөйләшүебез булыр дип кем уйлаган? 16 сентябрь көнне көндез 4 туларга 5 минутта инде гомере өзелгән булган апамның. 15ендә, авылда күршеләргә кереп, миңа шалтыраткан, сәгать 2ләрдә өйдә бик озак телефон шалтырады. Мин бер аяк белән телефонга килеп җитә алмадым. Нинди аяныч. Инде шушы көннән соң 5 ел вакыт ничек кирәк шулай үтеп китте.

Әле дә бүгенге көндә, кызы Камилә, оныгы Камил, Аллага шөкер, исән-саулар. Казанга килсәң, ишектән килеп керүгә, кочаклап каршы алалар, кайнар коймаклар пешереп, апа кебек сыйлап, озатып калалар. Өйдә бер әйберне дә урыныннан күчерми, әнидән ничек калган, шулай торсын, ди Камилә. Без аны бик сагынып, юксынып яшибез. Менә-менә йөгереп килеп керер дә, “Әйдә, бәлешеңне чыгар!” – дип көлеп җибәрер кебек. Килгәч, аның яткан һәм утырган урыннары аны юксындыра кебек. Бигрәк тә җәй көннәрендә бакчада бергә булган вакытлар сагындыра. Тыныч йокла, сине беребез дә – балаларың да, туганнарың да, авылдашларың да, халкың да онытмый, кадерле апам!

Аның турында истәлекләр берничә калын китап итеп язсаң да язылып бетмәс иде. Исән-сау булсам, лаеклы ялга чыккач, бу хыялларымны тормышка ашырырмын әле дигән өметләр белән яшим мин.

## “Очты аккош күкләргә...”

***Зәбир ҖАББАРОВ, җырчы.***



Мин үзем, үткән еллардагы сәхнә кешесе буларак, бүгенге көндә дә татар җыр сәнгате белән бергә яшим, андагы һәрбер вакыйганы, яңалыкны, концертларны күзәтеп барам, кемнәр сәхнәдән китә, кемнәр анда тәүге адымнарын ясый – кызыксынып торам. Тормыш бертуктаусыз дәвам иткән кебек, җыр сәнгате дә алга таба бара, хәрәкәт итә, олы җырчыларыбыз лаеклы ялга китә, бүген сәхнәдә яшь җырчылар күбәйде. Әмма язмам җыр сәнгатенең бүгенге торышы турында түгел, анысы аерым тема.

Аяз көнне яшен суккандай булды бу хәбәр... Вафирә Мөхәммәт кызы Гыйззәтуллинаның вафаты турында радио-телевидение игълан иткәннән соң, бөтен татар дөньясы тетрәнде, якты көннәр караңгыланып калды. Бу вакытта милләттәшләребезнең ни кичергәнен аңлау авыр түгел иде. Соңгы елларда авыр

югалтуларны күп кичердек шул, сәнгатебез күгендәге йолдызлар берсе артыннан берсе сүнде.

Вафирәбезне югалтуны да мин үзем бик авыр кичердем. Казан дәүләт консерваториясенең профессор Зөләйха Хисмәтуллина классында җыр-вокал серләрен өйрәнеп, Г.Тукай исемендәге татар дәүләт филармониясенә эшкә килгәч, Вафирә белән бер концерт бригадасына билгеләделәр мине. Аның белән озак еллар янәшә эшләргә, элекке Советлар Союзын иңләп-буйлап гастрольләрдә еш йөрергә туры килде. Бер гаилә кебек, бер-береңә терәк булып эшләү араларны үзеннән-үзе якынайта икән. Вафирәнең тирән белемле, киң эрудицияле булуына һәрвакыт сокланып яшәдем. Җырчы-артистка буларак, югары профессиональлеккә ия, ә сәхнәдә үз-үзен тотышын аккошка тиңләргә булыр иде.

Йөрәкнең әрнүен аңлатырга сүзләр таба алмыйм, бүген дә ул сәхнәгә килеп чыгар, радиодан чыгышлар ясар, яңа концертлары белән Камал театры сәхнәсенә килеп чыгар кебек. Милләтебез өчен көчен, җанын кызганмады ул. Бүгенге түбән зәвыклы заман шаукымына бирелмичә, аның һәрчак әйтер сүзе булды, җыр сәнгатебезнең профессиональлеге өчен көрәште. Вафирә белән бергә эшләүдән туктагач та, күп еллар буена телефоннан хәбәрләшеп, сәнгать турында фикер алышып яшәдек. Аның: “Зәбир, бергә эшләгән иптәшләр күптән инде бер-берсен онытып бетерделәр, бердәнбер синең тугрылыгың көчле булды, онытмыйча шалтыратуыңа рәхмәт”, - дигән сүзләре соңгы сүзләре булган икән...

Вафирәнең сәхнәдә басып торуы, аның сәхнә костюмнары, аның программасы, репертуары, башкаруы шулкадәр затлы-зәвыклы иде, ул бервакытта да “кычкырып торган” ятышсыз күлмәкләр кимәде, бу яктан башкалардан аерылып торды, тамашачы аның концертларыннан рәхәтләнеп ял итеп кайта иде. Чын-чынлап Идел кызы иде ул, Иделнең бер аккошы иде. Бик юксынам шул Идел кызын, Вафирәне. Яшьлек елларым, ул чактагы гастрольләрне, яшьлек җырларын нык сагынам. Җаның җәннәтләрдә булсын. Амин.

## “Җыр – моңы яши күңелемдә...”

***Михаил Апушев. «Юлдаш», сентябрь,2008 ел***

Татар халкының моңлы сандугачларының берсе Вафирә Гыйззәтуллина фаҗигале төстә арабыздан китсә дә, аның турында якты истәлекләр күңелләрдә яши. Бигрәк тә туган җире – Менделеевск районының Камай авылындагы туган йорты һәм зираттагы кабере авылдашларында аның турындагы хатирәләрне яңартып тора. Бүген ул йортта мәшһүр җырчының бертуган энесе – Мансур яши. Ул апасы турындагы якты истәлекләре белән уртаклашты.

Мансур Мөхәммәтдин улы Гыйззәтуллин 1956 елда гаиләдә 7 нче бала булып дөньяга килгән. Авылда әти-әнисе белән яшәгән. Аларны да, апасын да соңгы юлга озату хәстәрен ул күргән.

**- Мансур абый, апагыз күңелегездә нинди булып кереп калды? Гади бертуган буларакмы, әллә бөек кешеме?**

- Вафирә апа танылган җырчы булса да, без – туганнары янында гаиләбезнең гади бер әгъзасы, игелекле, ярдәмчел апа булды. Безнең тормышыбыз белән даими кызыксынып торды. Авырлыклар, борчулар килсә, юатырга, тынычландырырга, көченнән килгән кадәр ярдәм итәргә тырышты. Авылны бик яратты ул. “Монда кайтып яшәп китүдән җаныма тынычлык табам, рухый ләззәт алам”, - дип әйтә торган иде.

1999 елда әниебез үлде. Вафирә апа аны җирләгәч, 40 көнен уздырганчы монда яшәде. Миңа киңәшче дә, ярдәмче дә булды. Безнең якларга концерт белән

килсә, өйгә кагылмыйча калмый иде. “Тиздән язучылар белән очрашуга киләбез. Мин алдан кайтам. Бер-ике атна монда торып китәм әле”, - дигән иде. Әмма андый очрашуны күрү насыйп булмады.

**- Вафирә апаның фаҗигале үлеме турында кемнән, кайчан ишеттегез?**

- 2002 елның 16 сентябре иде ул. Көн кичкә авышкач, Чаллыда яшәүче туганнан туган сеңлем Нурия өйгә килеп керде дә: “Мамадыш юлында Вафирә апалар һәлакәткә очраганнар. Апа үлгән, ә кызы авыр хәлдә икән”, - диде. Бу хәбәр мине бертын өнсез итте. Нәрсә әйтергә дә, нишләргә дә белми тордым. Барча туган-тумача җыелып, аның җәсәден алып кайтырга киттеләр. Миңа өйдә булырга, җирләр өчен барлык әйберләрне хәстәрләргә, кабер урынын билгеләргә куштылар.

**- Вафирә апа мәшһүр җырчы иде. Аны Казанның берәр зиратында җирләсәләр, кадер-хөрмәт зуррак булмас идеме?**

- Казанда зур кешеләр арасында, аның каберенә дә урын табылыр, бәлки дуслары ешрак барыр иде. Әмма ул үзе һәрвакыт авылны яратып яшәде. Исән вакытында үзе: “Миңа зиннәтле калалардан Камай кадерлерәк, каберем авылымда булсын”, - дип әйтә торган иде. Биредә дә аның кабере һәрвакыт каралып тора. Туган көннәрендә дуслары, барча туганнар җыелабыз, искә алабыз. Монда да ул онытылмый, һәрвакыт сагынып яшибез. Вафирә апа үзе безнең белән булмаса да, аның җыр-моңнары, ачык күңелле, мөләем, ярдәмчел кеше буларак образы безнең күңелләрдә яши һәм мәңге яшәячәк тә. Аның якты истәлеге авылда киләчәк буынга җиткерелә. Ул халык күңеленнән барыбер җуелмас.

**- Сез ничә бертуган үстегез? Арагызда җырлаучылар бармы?**

- Без гаиләдә сигез бала үстек. Олы абыебыз Харис хәзер пенсиядә, Менделеевскида яши. Аннан соң Гариф абый. Ул Ташкентта яши иде, шунда кинәт үлеп китте. Өченчебез Вафирә апа иде. Ул да, белгәнегезчә, бүген бу якты дөньяларда юк инде. Аннан соң Әлфирә, Түбән Камада яши, тавышы матур, җырларга бик ярата. Гаиләбезнең бишенче баласы – Роза исемле апам. Ул да Түбән Кама шәһәрендә яши. Клубта эшли, ансамбльдә җырлый. Аннары – Рабига, Чаллы театрында режиссер булып эшли. Быел Төрекмәнстанга барып, анда диплом алып кайткан. Мин гаиләнең җиденче баласы. Авылдан беркая да китмәдем. Бүген терлекче булып эшлим. Иң төпчегебез Гүзәлия исемле. Казанда яши, эшмәкәр. Ул да җырларга ярата. Аннан соң Вафирә апаның кызы Камилә дә җырлый бит. Гаиләбез, гомүмән, җырга сәләтле булды.

**- Бу сәләт сезгә геннардан киләме? Әти-әниегез җырлыйлар идеме?**

- Әтиебез гармунчы иде. Үзе уйнап, үзе җырлап, мәҗлесләр алып бара иде. Аның җыр-моңга тартылуы безгә дә күчкәндер инде. Кечкенәдән әтигә кушылып җырларга яраттык. Мәктәптә укыганда апаларым да, сеңелем дә, без, малайлар да, үзешчән сәнгатьтә бик актив катнаштык. Мәктәптә, авыл клубында үткән тамашаларның берсе дә бездән башка узмады. Өйдә бергә җыелсак, хәзер дә җырламыйча утыра алмыйбыз. Җыр-моң белән тормыш күңеллерәк бит ул. Мәҗлесләрдә дә шулай. Җырлап-биеп алгач, бер бушану кичерәсең, бөтен борчу, сагышларың онытыла бит.

**- Вафирә апа аргызда иң матур җырлаучы идеме? Ул гына ничек олы сәхнәгә чыга алды?**

- Апа Алабуга мәдәният-агарту училищесын бетерде дә, авылда клуб мөдире булып эшләде. Ул вакытларда төрле җыр смотрлары, бәйгеләре бик күп була иде. Апа үзе ялгызы да җырлый, матур җырлаучы авылдашларны да андый

бәйгеләргә алып бара иде. Аның коллективы районда беренче булды. Шулай ул бервакыт Казанда үткән зур бәйгедә җиңү яулады. Шунда аны жюри әгъзалары сәләтен күреп алып, Казанга чакыралар. Укырга, тагын да үсәргә мөмкинлек тудыралар. Шулай итеп, ул озак еллар Казанның зур сәхнәләрендә халыкка көймоң җиткерде.

Вафирә апаның тавышы, чыннан да, аеруча көчле, матур иде. Аннары ул үзе дә җырга бик бирелгән кеше иде. Ул җырламыйча бер дә тора алмас иде. Үзе өстендә дә бик нык эшләде. Эзләнүчән, тырыш кеше иде ул. Сәхнә аның өчен туган йорт, әткә-әнкә тирбәткән бишек кебек якын булды. “Сәхнәдән аерылсам, мин халкымнан аерылам, ә соңгысы минем өчен фаҗига”, - дип әйтә торган иде. Пенсиягә җибәрүләрен бик авыр кичерде. Бүтән җырлатмаслар, сәхнәгә менгезмәсләр, дип курыкты, күрәсең.

**- Вафирә апа соңгы вакытларында концертларын куйдырмаулары турында борчылып матбугатта да язып чыккан иде. Бу аңа аяк чалу булдымы, әллә татарга хас көнчелек идеме?**

- Апа матур җырлаву өстенә, туры сүзле, милләт өчен җан атучы кеше дә иде. Ул милли хәрәкәт лидерларының берсе булды. Ул сөйләгәннәрдән белгәнемчә, Казанның Ирек мәйданында халык милли азатлык өчен көрәш таләп итеп, митинглар үткәргәндә ул җырлап, халыкны тынычландырып торган. Халык арасында кызып китүчеләр булып, татар халкына каршы кешеләр белән низаг килеп чыгып, зур фаҗигагә әверелмәс өчен эшләгән ул аны. Ул җырлаганда барча җыелган кеше тып-тын калып тыңлаган. Аның моңлы тавышының халыкны үзенә тарту, сокландырып, җәлеп итү көче дә бар иде. Ул, гомүмән, кайда гына җырласа да, кешеләр тынып кала, йотлыгып аны тыңлый торган иде.

Вафирә апа авылда да милли мәсьәләне күтәреп, җыеннар үткәрде. Бигрәк тә, Татарстанның суверенлыгын яклап, референдум үткәргәндә халык белән күп очрашты. Милли азатлыкның нәрсә бирәсен халыкка җентекләп аңлатты. Безнең районда гына түгел, ә башка төбәкләрдәге авылларга барып, концертлар куеп, халыкка аңлату эше алып барды. Шул туры сүзле булуы кемнәргәдер соңыннан ошамый башлады. Шулай да аның концертлары пенсиягә чыккач та куелды. Казанның С. Сәйдәшев исемендәге Зур концерт залында ике сәгатьтән артык үзе генә җырлап, концерт куйды. Авылларда да көтеп алынган җырчы иде ул.

**- Сез хәзер 6 бертуган калгансыз. Алар сезнең янга, туган йортларына еш кайталармы?**

- Барысы да кайталар. Бигрәк тә олы бәйрәмнәрдә, Корбан гаете көнендә. Әти-әнинең, Вафирә апаның каберендә булабыз.

## Вафирәне дога, мөнәҗәт, җыр белән искә алдылар...

**Интернет челтәреннән, 26 сентябрь , 2008 ел**



Казандагы Шәрык клубында Татарстан һәм Каракалпак республикасының халык, Россиянең атказанган артисты Вафирә Гыйззәтуллинага багышлап авыз ачу, ягъни ифтар чарасы узды.

**Җиде ел элек булган фаҗига**

Сентябрь аенда Вафирәнең салкын гүргә керүен һаман да күп санлы тыңлаучылары авыр, үкенечле хәбәр итеп искә төшерә. Ул вакытта Бондюг кызы Вафирә авылынннан кайтып килә

торган булган. Серле шартларда автомобиль һәлакәтенә очрап арадан китүенә инде җиде ел элек вакыт узган. Аның тормыш юлына вакытыннан алда нокта куелуны, сәяси эшчәнлегеннән дә күрүчеләр бар. Казанда узган очрашуда да, җырчы Вафирәнең милләтпәрвәрлеге, халыкны яклап йөрүен искә еш төшерделәр.

**Халыкны рухын күтәреп йөргән**

“Башкалар бәйрәм, табын өстәле җырчысы булганда, Вафирә Гыйззәтуллина “Ком бураны”н җырлап, халкыбызның рухын күтәрде”, дип искә алды галим Равил Һади.

Бу фикерне чарага килгән башкалар да яклады. Ә хокук белгече Галишан Вәлиәхмәт үзен җыр сөюче, дип таныштырды. Вафирәне ул беренче чиратта сәяси карашлары һәм кешелек сыйфатлары өчен үз итеп искә ала.

**Татар мәдәниятен яклаган**

Вафирә Гыйззәтуллина кызы Камилә һәм туганнары каршында хәтирәләр яңгырады. Аны “бик матур тавышлы”, “чибәр”, “чын йолдыз” булган актриса дип искә алдылар. Бу сүзне сәхнәдәш дуслары да кабатлады.

Җырчы Флера Сөләйманова да Гыйззәтуллинаны, бар татар мәдәниятенең яклаучысы иде, дип сөйләде. “Ул миңа да Татарстанның атказанган артисты дигән исем алып бирде. Вафирә сәхнәдә дә, мәйданда да халыкны үзенә ияртә белүче лидер иде”, диде ул.

**Туксанынчы елларда туган яшьләр Вафирәне каян ишетсен?**

Вафирә җитмешенче еллар уртасында танылу алган. Аннары тагын берничә дистә ел сәхнә түрендә торган. Тик туксанынчы елларда туып үскән яшьләр аны белми икән. Кичәне алып баручы Азат Нурмөхәммәтов аларга җырчының тарихын сөйләде.

Ә бүгенге 17-18 яшьлекләр үскәндә телевизордан һәм радиолардлан Вафирә Гыйззәтуллина иҗаты актив формада пропогандаланмаган. Килүчеләр, Вафирә дисклары да сатуда да юк дип зарланды. Кызы Камилә кунакларга үзендә сакланган язмаларны күрсәтте. Шулай ук берничә моң сөюче яшь кеше төрле җирләрдән табылган язмалары барлыгын әйтте.

**Флера Сөләйманова мөнәҗәт сөйләде**

Флера Сөләйманова “Вафирә рухына дога булып барып ирешсен” дип “Сабырлык” исемле мөнәҗәт сөйләде. Чакырылган хәзрәт тә шул максаттан дога кылды.

**“Туган тел”не басып җырладылар**

Чарага татарча итеп киенгән өлкән яшьтәге самими апалар да шактый килгән иде. Алар башкаларны дүләнә, лимонник ише бакча җимешләре белән дә сыйлады. Апалар дога кылып утырды. Аннары исә яшьлекләрен искә төшереп җырлап утыра башладылар. “Ком бураны”, “Зиләйлүк”, “Күзге җыр” сүзләре яңгырады. Дәррәү басып “Туган тел” җырын җырладылар. Вафирә Гыйззәтуллина да милли җырны шулай бастырып җырлата торган булган.

## “Кукмара, машина”

***Алмаз Хәмзин, 15.09.2009 ел.***

Вафирә Гыйззәтуллина дигәч, гастрольдә йөргән тузанлы юллар искә төшә. Әле дә хәтеремдә: элекке Апас районына кергән Чүти авылыннан район үзәгенә кайтып килешебез. Инде ничә көн җиргә бер тамчы яңгыр төшмәгән, юлларны тузан каплаган. Ялгыш берәр машина үтеп китсә, качып калам димә, тузан йотып тончыгачаксың. Ярый әле, урамдагысы кайчан да булса тарала, ә автобуста

чыдарлык түгел. Автобуска бер көтү халык, без, артистлар, төялгән. Вафирә каяндыр марля табып, авыз, борын, колакларын томалап бәйләгән дә, күзләрен генә чепелдәтеп, бер ярыктан миңа карап бара. Маңгаеннан аккан тиренә кара тузан ябышкан. Күрәм, сизәм, аңлыйм. «Алла каргаганмы әллә бу артист тормышын» дия сыман ул. Юллар Вафирәне әле тагын кайларга илтер, ниләр күрсәтер? Әйе, җырындагы кебек:

Юллар, юллар, авыр булса булсын,
Тик соңгысы гына булмасын!

Тик соңгысы гына булмасын, дигән идең дә… Кукмара юлларындагы һәлакәт искә төшә. Анда да исән калган идең бит югыйсә, һәлакәтләрдән исән-имин чыккач, без һәрвакыт шаярабыз. Утсыз, сусыз, салкын Балтачның элеккеге «данлыклы» кунакханәсенә кайткач, минем шигырьне кабатларга ярата идең. Ничек әле? Ә-ә, менә болай:

Потомушты су да юк,
Потомушты ут та юк,
Потомушты без бу илнең
Бәхетле балалары!…

Шулай, Вафирә, безгә әле бу илдә “бәхетле” булып һаман яшәргә туры килә. Синең җырыңдагыча булса, әйбәт булыр иде дә бит...

### *“Ка-а-к”*

***Алмаз Хәмзин, «Сәхнә», 2011, №10 (октябрь)***

Вафирә Гыйззәтуллина белән иртә яз башланган гастрольләрнең көзге соңгы концерты Балтач районының Сасна авылы клубында бара. Ямьсез явымлы көннәр. Инде концертны башлар вакыт та җитте, ләкин залда тамашачы йөзгә дә тулмау сәбәпле, Вафирәнең кәефе сүлпән, концертны куярга киреләнеп маташа. Мин ишек төбендә билет ертучы булып торам. Бер аягым клубның залында, икенчесе урамда. Әле бу Сасnаның иске клубы. Ишек ачык, тупсасы җиргә сеңгән. Баш очында караңгы урамны яктыртып бер лампочка яна. Шул вакыт әллә кайдан ап-ак ата каз пәйда булды. Тамак аслары салынган – пекин токымы. Бик җитди кыяфәт ясап килде-килде дә мине санга сукмыйча муенын эчкә сузып: «Ка-а-а-к» – дип куйды. «Менә ни как, – мәйтәм, – Вафирә концертны башламый». Халык көләргә тотынды. Нигә көләләр икән дип Вафирә чыкты. Менә, мәйтәм, каз килде, нишләп башламыйсыз, ди. Бу хәлдән соң Вафирәнең күңеле күтәрелеп китте, концертны башлап җибәрде. Гадәттә, ул җырлаганда мин чәк кенә ишек төбендә сакта торам да бераздан үзем дә сәхнәгә чыгарга әзерләнәм. Чират миңа. Җырлап җибәрүем булды, залда утыручы бер абзый «Ка-а-ак!» дип куймасынмы. Китте көлү: халык көлә, мин чыдый алмыйм. Булмый җырлап, башлыйм гына, теге каз искә төшә дә тагын пырхылдыйбыз. Вафирә сәхнәгә чыгып тынычландырып та карый, нишлисең, бөтен халык белән көлүгә бүселәбез дә китәбез.

– Ярый, – ди Вафирә, – үзем җырлыйм, бар, тынычлан, ди. Әйбәт кенә онытылып җырлый башлыйм, тегеннән тагын берсе «Ка-а-ак» дип куймасынмы. Зал тагын гөрселдеде. Мине әйткән дә юк. Ул көнне җырлап булмады. Ләкин халык: «Мондый шәп концертны әле гомер буе күргән юк иде», – диеп калды.

### **“Кадер хакын беләбезме?..”**

***Хуҗахмәтова Ф.Ә. Язылмаган роман, 2009ел.***

Без аның белән беркайчан да якын дуслар булмадык. Ахирәтләргә кушылмадык, елап аерылышып, кочаклашып күрешмәдек. Ходайның хикмәте, Түбән Камага нигез салынасы елны очраштык та, инде менә гомер буе бер-беребезнең барлыгын тоеп яшибез. Хәер, кирәклек, дип әйтү әле ул, бәлки, дөрес тә түгелдер. Чөнки була шундый чаклар: елга бер дә, ике дә була ул, очрашабыз да сөйләшеп туя алмыйбыз.



Менә сентябрь аенда ул үзе – Вафирә Гыйззәтуллина шалтыратты. Без күрешмәгән, очрашмаган арада җәй булып, җәй узып киткән. Көз җиткән. Сөйләшергә сүз дә юк кебек, ятсынышканбыз.

- Кил әле, бер әйбер күрсәтәм,- ди ул, ничектер серле итеп.
- Йә, әйт инде, шигырь яздыңмы, көй чыгардыңмы? – дим мин.
- Юк, - ди Вафирә. – Аны әйтеп булмый, күреп кенә була. Сиңа ошаса, башкаларга да күрсәтербез. Кызык ул, үзең дә шаккатарсың, - дип кызыктыргач, ничек бармыйсың инде. Вафирәнең яңа җыр өйрәнсә, йә шигырь язса, башта иң беренче миңа җырлап, уйнап, сөйләп күрсәткән чаклары еш була. Андый көнебез бәйрәмгә әйләнә, чөнки Вафирәнең җырлавын бик яратам. Соңгы елларда да яңа һөнәре (һөнәр генә түгел) ачылып китте. Яшәүнең мәгънәсен эзләгәндә, чит-ятлар аның иреген буганда, җаныннан, йөрәгеннән саркып көй чыга.

Күз алдына Сара апа килә. Ул да нәкъ менә шундый чагында көй яза башлагандыр. Аңардан да шулай көлгәннәр, авыр сүзләр ишеттергәннәр, санламаска, зурламаска, кадерләмәскә тырышканнар. Иҗат кешесен күрмәмешкә салышу – үзе шул кадерләмәү билгесе.

Үзем Вафирәгә барам, үзем Сара апа Садыйкова турында уйлыйм. Юксындыра, сагындыра Сара апа. Әгәр дә бүген урамда калфак киеп йөргән хатын-кызларны күрсә, ничек шатланыр иде. Вафирәгә дә, безгә дә бик тә калфак кидерәсе килә иде аның.

Агачлардагы сары, серле төсләр уйларымны Вафирәгә кайтара. Нәрсә күрсәтмәкче икән, әллә берәр картина иҗат итеп куйганмы? Шунысы ачык: Вафирә мине күлмәк, алка, муенса күрсәтергә чакырмый. Бу дәшүендә нинди дер хикмәт бардыр?! Чыннан да, шулай булып чыкты. Килеп керүем белән:

- Менә мине күр әле, - дип, бер рәсем-портрет күрсәтте. Күрдем дә исем китте: бу – Вафирә Гыйззәтуллина, аның иң матур чаклары. Арада 15 елдан артык вакыт ята. Өстендә беренче затлы, кыйммәтле концерт күлмәге. Ул аны әллә инде 20 метр сары шифоннан тектергән иде. Озак кына текәлеп карап торсам да, берни дә аңлый алмадым.
- Кайдан бу, кем хезмәте?
- Әй, әнә, чүплектән тапканнар!
- Әй, сөйләп торган буласың инде, - дим мин дә аның төсле итеп.
- Чыннан да шулай ...

Дөрестән дә шулайрак булып чыга шул

31 август көнне Вафирә белән шагыйрә Лена Шагыйрьҗан Болак буена йөрергә чыгалар. Туйлар узган, бәйрәм үткән. Республика көнен уздырган шәһәрне гадәти тормышка кайтаралар. Кемдер такта, кемдер шар, кемдер кемнеңдер афишасын эләктерә. Шунда, гадәттәгечә, Вафирә дә бер иргә:

- Нәрсә, дачаңа фанера эләктермәкчеме, - ди. Ленага андый сөйләшүләр ошамый, ачулана.

- Юк, Вафирә, минем дачам юк,без Казан шәһәренең иң уртасында, иң шәп трущобада торабыз,- ди теге ир.– Шулай да бездә синең бик матур портретың бар...

Шул арада бу ирнең хатыны да килеп җитә, алар да йөрергә чыкканнар икән. Танышып китәләр. Ир – Фоат, ә аның хатыны Фәһимә атлы. Островский урамы башындагы бик иске йортта гомер итәләр икән. Биш-алты ел элек, бәлки җидедер, төгәл генә әйтеп булмый, чүп чиләген түгәргә чыккан Фоат зур гына бер портрет күтәреп керә. Аны күреп, Фәһимә дә телсез кала. Бу табылдык аларда, кысан җиргә тана башы, дигәндәй, байтак кына эленеп тора. Беркөнне Фәһимә ханым иренә:

- Стенага каратып куй әле, әллә ничек, күзләре бигрәк моңлы, безгә рәнҗидер кебек,- ди.

Шуннан аны сарайга күчерәләр, менә-менә яңа, иркен квартира алырбыз да түр башына эләрбез, дип хыялланалар. Ә фатир юк та юк.

- Без әле аны, матур рам ясатып, бенефисыңа да илтергә уйлаган идек, ачуланырсың кебек тоелды, - диләр Фоат белән Фәһимә. – Без сине бик яратабыз, Вафирә, үзеңне, җырларыңны, - ди Фәһимә ханым. – Ә моны теләсәң – ал, безгә яңа квартира насыйп түгел, күрәсең, - ди ул, моңсуланып.

- Мин аларга бер сүз дә әйтә алмадым, әллә нәрсә булды шунда, - ди Вафирә ханым.

Еллар сөреме, вакыт тузаны күмеп китә алмаган, җил-яңгырларга, дымга, эссегә, суыкка да исе китмәгән үз сүрәтен күтәреп, җырчы атлый. Кайсы явызы аны шулай чүплекләргә чыгарып ыргыткан да кемнәр аны шулай яңа гына эшләнгән төсле итеп саклаган. Кайларда эленеп торды икән ул, кемнәргә җан җылысы сирпеде, яшәү көче бирде икән? Кинәт кенә кемгә аның кирәге беткән? Әллә ул кеше инде бу дөньяда юкмы? Кем хезмәте соң бу? Фото да кебек, түгел дә кебек. Төсле дә шикелле, түгел дә шикелле.

Вафирә үзе шулай утырып рәсемгә төшкәнен дә хәтерләми. Әллә берәр оста сәхнәдән төшереп алганмы? Сораулар да, фаразлар да бик күп. Ничек кенә булса да, килүем бушка түгел. Мин бу серле табышны газета укучыларга да күрсәтергә ниятләдем. Ул сәнгать әсәре кебек, аңа карап сокланырга була. Әлбәттә, бу рәсемне берәр рәссам эшләсә, ул киләчәк буыннарга калыр иде. Алар исә әлегә бай хатыннарының портретларын ясау белән күбрәк мәшгуль. Чөнки рәссамда да тамак кайгысы. Язучы, җырчы, кыскасы, татар иҗат әһелләренең портретларын ясаганга кем акча бирә. Шулай да рәссам Әхмәт абый Китаев Сара апа Садыйкованың портретын ясаган булган. Бүген ул – кыйммәтле, затлы бер хәзинә. Бездә шул, нәкъ бөек Тукаебыз әйткәнчә, кадереңне белсеннәр өчен үлеп күрсәтергә кирәк. Бүген Сара апа Садыйкова бик кадерле дә соң, ә аны аз типкәләделәрме? Тормышы көрәштән торды, көрәшеп, җырлары белән мәңгелектән урын алды.

Вафирәне дә типкәләмәкчеләр: әнә журнал бәйрәменә чакырганнар: “Фафирә” дигәннәр. Телевизордан бик матур яңа язмалардан концерты булды. Программага: “Р.Үтәй җитәкчелегендәге оркестр концерты” дип язганнар. Югыйсә, анда Вафирә Гыйззәтуллина 7 җыр башкарды, аның концерты булды.

Вак-төякме? Бәлки шулайдыр да. Ләкин мондый вак-төякләр күбәеп китсә, кешегә авыр була башлый.

Вафирәгә күп кирәкми. Аңа бары сәхнә, сәхнә генә дә түгел, тамашачы кирәк. Зур акчалар да сорамый, кая чакырсалар, шунда бара: Ивановомы, Төмән, Иркутскимы? Ерак дип тормый, бара, җырлый. Ә җырлары туйдырмый, рәхәтләнеп тыңлыйсың.

Бу очрашуыбыз да бик истәлекле булды. Вафирә миңа яшьли вафат булган, шулай да җирдә үзенең чын шагыйрә булуын исбатлап киткән Саҗидә апа Сөләйманова шигыренә язган яңа җырын үзе уйнап, үзе җырлап күрсәтте. Гаҗәп! “Әйдәгез, Саҗидә апа Сөләйманованы искә алу кичәсен үткәрәбез”. Улы Әнвәр Маликовка шулай дип шалтыраттык. “Үткәреп булмас, хөкүмәттә акча юк”, - ди Әнвәр. Акча бар ул, аны табып була. Кеше кадере юк. Үзеңне кадерләп кенә зур булып булмый. Саҗидә апа шигырьләренә язылган җырларны башкаручы артистларыбыз аның кичәсенә килеп җырлаган өчен акча сорармы икән? Юк, сорамаслар.

Безнең халыкта бер мәкаль бар: чишмә кадере кипкәч арта. Югыйсә, чишмәләр бит кипми, алар кешеләрдән әллә оялып, әллә хурланып, качалар, югалып торалар. Әнә Әлмәт якларында чишмәләрне барлый, саклый башлаганнар. Ә талантларыбызны кайчан саклый, яклый, кадерли башларбыз соң?!



## “Күзге моң булып калды...”

***Хуҗахмәтова Ф.Ә. Язылмаган роман, 2009ел.***

Вафирә Гыйззәтуллина гаять күпкырлы талант иясе иде. Ул җырчы гына түгел, шагыйрь, композитор да. Гаҗәп кызыклы, булдыклы, уңган кеше иде. Күп, бик күп нәрсәләргә өлгерде ул. Хәтта хушлашу концертын да күрсәтте. Ул концерт 2000 елның көзендә Салих Сәйдәшев исемендәге Зур концерт залында узды. Концертны үзе оештырды, үзе сценариен язды, үзе җырлады. Тамашачы да куркып калды бугай. Ул концерт иң шәп композиторларның көйләреннән һәм халык җырларыннан, Вафирәнең үз җырларыннан тора иде. Ә Вафирә җырларны сайлый белә. Рөстәм Яхин, Фасил Әхмәтов, Нәҗип Җиһанов, Салих Сәйдәшев, Ринат Еникеев, Әгъзам Фәттах, Алмаз Монасыйпов, Исмай Шәмсетдинов – Вафирәнең яраткан композиторлары. Ул аларның җырларын җырлады. Халык җырларыннан “Дранча”ны да җырлады. Ничек ул аны калдырсын? Концерт искиткеч югары дәрәҗәдә һәм зәвыклы иде.

... 1964 ел. Казанның Муса Җәлил исемендәге опера һәм балет театрында үзешчәннәр концерты. Зифа буйлы, айдай яктылык, нур сибелеп торган түгәрәк йөзле сөйкемле кыз борынгы көйләрдән “Дранча”ны җырлый. Вафирә бу җырны үзенә кадәр башкаручыларга аз гына да иярмичә, үзенчә, гади, саф, моңлы, дәртле итеп башкаруы, сәхнәдә үз-үзен тотышы белән тамашачыны сокландыра. Мәскәүдә Кремльның Съездлар сараенда да шул җыр белән Бөтенроссия смотрында лауреат булып кайтты.

“Гөлҗамал” белән “Зиләйлүк”не, “Бөдрә таллар”ны калдырсынмы? Аны бит шушы борынгы татар халык җырлары җырчы итте, гомер буе озата йөрде.

1973 ел ел. Консерваториянең бишенче курсында укып йөргән чак. Группадашы баянчы Рәшит Мостафинга серен ачты.

- Воронеж шәһәрендә Бөтенсоюз халык җырлары һәм уен кораллары бәйгесе була. Әйдә, шунда катнашабыз, - диде.

Рәшит Вафирәне шаярта дип уйлаган иде дә, аның исә томырылып карашыннан ук: “каршы килеп кенә кара, белермен мин сине нишләтергә”, дигәнне укып, “Әйдә”, дими чарасы калмый. Монысын миңа соңыннан, күп еллар үткәч сөйләгән иде Рәшит. Алар өчәү: Таганцева Галина һәм алар икесе бергә барганнар. Бөтен союздан җыелган 70 кә якын җырчы арасыннан иң останы сайлаганнар: халык җырлары, кайсы гына милләтнеке булса да аңлашыла икән. Зур симфоник оркестрның бүгенге дирижеры Владимир Федосеев конкурсның жюри рәисе. Ул үзе дә Мәскәү консерваториясенең баян классын тәмамлаган. Кирәгеннән дә артык таләпчән һәм җаваплы кеше.

Вафирә Гыйззәтуллина – “татарка” җырлый. Барысын да – урын бүлүчеләрне дә, катнашучыларны да – бармак төртеп, беренче урын әнә шул кызга булачак, дияр дәрәҗәгә җиткерерлек итеп җырлый. Җырлый Вафирә, сибелә татар җырлары: “Бөдрә таллар”, “Зиләйлүк”, “ Гөлҗамал”. Әле башка милләт балалары кебек затлы киендереп, тәмле ашатып, машиналарда гына йөртсәләр, нишләмәсләр иде. Барысы да үз исәпләреннән бит. Ә алар барыбер җиңә. Вафирә – лауреат, Рәшит – дипломант була ул конкурста.

- Шатлыктан нишләргә дә белмәдек, безне анда шулкадәр зурладылар, мактадылар. Ә без ышандык, - ди Рәшит, - ышандык та Казанга телеграмма бирдек: “ Ура, мы лауреаты!” Җиңүебез шатлык китерер, чәчәкләр белән каршы алырлар, дип уйлаган идек. Бездәме соң ...

Ә шулай да Бөтенсоюзда татар халык җырларын беренче урынга чыгару гомерләре буена Вафирәне дә, Рәшитне дә озата йөреп, халкыбызның бәгырендә урын алырга булышкандыр.

“Киек казлар”, “Аккошлар”, “Ай, былбылым”, “Сандугач”, “Гашыйк бул син миңа”, “Бөтен нәрсә сине хәтерләтә”... һәм, әлбәттә, “Бәхет”. Бик ашыгып язам, авторларын бутармын дип куркам, ә Вафирә бутамый һәм аларга бик сак килә иде. Гомер буена ул язучыларга тартылды, газета-журнал укыды, аларны пропагандалауда катнашты. Махсус зур-зур программалар эшләп, Габдулла Тукайга, Муса Җәлилгә, Бөек җиңүгә махсус концертлар багышлады. Бу соңгы концертында Вафирә язучы Кояш Тимбикова сүзләренә язган үз көен – “Кышларга да бергә керсәк” дип залны елатты.

Инде сүзен дә, көен дә үзе язган “Моңнарымны сезгә тапшырам” дигән җыр елатмады, елап булмады, тетрәндерде.

“Төнен елыйм, күрмәсеннәр диеп,
Кайчак төннәр буе тырмашам.
Ап-ак бураннарда чыгып китеп,
Такташ “Алсу”ыдай адашам.

Гомер узды дөреслекне эзләп,
Тик тапмадым – нинди аяныч.
Ә шулай да өметемне өзмим,
Сезгә җырлыйм – миңа куаныч.

Кызганмагыз мине, кызганмагыз,
Үзем сайладым мин язмышны.

Каргышлымы ул, әллә сагышлымы,
Яраттым мин, дуслар, тормышны.

Башым иеп, Аллаһыма киләм,
Гафу кыл, дияргә ашыгам.
Гомерем буе йөрәгемдә йөрткән,
Моңнарымны сезгә тапшырам".

Моңа өстәп берни дә әйтеп булмый, барысы да сыйган. Зал аягүрә басты, и-и, рәхмәт яугыры, мәдәният министры Илдус Тарханов йөгереп сәхнәгә менде, ярый әле, янында буш грамота кагәзе булган, ложада язып, шуны тапшырды. Вафирәнең бик күп очракларда әйтеп куя торган сүзләре бар. Бу очракта "Никтер безнең язмыш шундый инде" дигәнгә туры килә. Шул басудан без утырмадык – "Туган тел"не бергә җырладык. 1989 елда, Татар иҗтимагый үзәге файдасына концерт куйганда, беренче мәртәбә шулай җырлаган идек. Башка җырчылар да кабатлады, ләкин "тыелган" 4 нче строфаны беренче булып ул җырлаган иде.

Тагы ярты елдан Вафирәнең 55 яшьлегенә бенефис концерты булды. Ләкин инде ул кайтышрак чыкты, зур җырчының соңгы концерты ярты ел элек булган иде.

* * *

Зәмһәрир салкыннарын, ямьсез давылларын артта калдырып кышның иң матур чагына килеп җиттек. Җылы карлары, ак мамыктай бураннары белән февральгә килеп кердек.

И-и, үзе исән булса, 13 февраль көнне Вафирәбезгә дә 60 яшь тулыр иде. Көне буе чип-чиста итеп өен җыештырыр, өстәл тезәр, бик тәмле зур бәлеш пешерер, өе генә түгел, подъезды хуш искә тулыр иде. Баянын күтәреп Фасил абый Әхмәтов килер, җыр турында сөйләшер иде. Шагыйрь Рәшит Әхмәтҗанов, бергәләп азатлык өчен көрәшеп йөргән Марат абый Мөлеков, язучы Кояш апа Тимбикова, актриса Фирдәвес Хәйруллина... Чү, йә, Раббым. Болар бит барысы да Вафирәгә, Вафирә аларга терәк булган кешеләр. Инде алар да күченгән. Саҗидә апа Сөләймpraвованың да үлемен авыр кичергән иде Вафирә. Ул аның шигырьләрен яттан сөйли иде.

"Мин бит кошлар нәселеннән,
Төшләремдә очам кош булып", -

дия иде. "Кеше" урынына "мин" сүзен куеп. Бервакыт: "Тормышлар ничек, Вафирә?" – дигән идем.

"Тормышым минем авыр арба –
Йөгем һаман арта бара.
Арбам күптән туктар иде
Мәхәббәтем тартып бара", -

дип сөйләп китте дә: "Фәнис абый Яруллин", - диде. Әйе, ул аның да бик күп шигырен яттан белә иде. "Аның иҗаты миңа яшәү көче бирә", - дия иде. Ике аяксыз, чибәрләрнең чибәре Шаһидәсе үзе ни тора. Вафирә аңа да барып йөри, үзенә дә чакыра, концертларының беренче рәтенә китереп утырта. Аннан соң ирле-хатынлы, яхшы күңелле, Вафирәнең гаиләсенә исән чакта да, инде үзе вафат булгач та терәк булган Хәйдәр белән Нурфияне чакыра иде. Алар 25-30 ел элек, Нурфия әле филармониядә баш бухгалтер булып эшләгәндә дуслашып киткәннәр. Бүген алар: Камиләгә – ярдәмче, Камилгә – дус, иптәш, өлкән апа, өлкән абый.

Бер рәтне тутырып, чәчәкләр күтәреп Республика клиник больницасы врачлары килеп утырыр иде. Ул анда еш булды, җиде операция генә кичте, ә тамашачылар сизми дә калды.

* * *

Ул аны шундый көткән иде. Алдан әле аның малай булуын тели-тели тууын көтте. Аннан соң мәктәпкә китүен көтте. Нинди матур балалар киеме бар – шуларны алыр иде дә, журналда гына була торган кебек итеп киендереп куяр иде.

Кайчак кызы Камилә дә:

- Кыландырма инде шулкадәр, ул бит сиңа курчак түгел, - дияр иде.

- Шатлыгым, бәхетем, - дияр иде әбисе.

Бишек җырын җырлап йоклатыр да, Шүрәле, Су анасы булып уйнатыр иде.

- Әбием, мин алардан туйдым инде, син миңа үз әкиятеңне сөйлә, - дияр иде оныгы. Андый чакларда аны әбисе үзенең балачагына, туган авылына алып китәр иде. Камил инде Камайның бөтен матур урыннарын яттан белә иде. Никтер барыбер туймады ул әбисенең хикәяләреннән. Әбисе Камилнең туган көнен үткәрергә әзерләнә башлады.

- Бөтен классташларын чакырабыз, истә калырлык итеп үткәрәбез, - диде.

Камилә каршы төште, “И-и, әни, болай да акча юк”, - диде Камилә. Саклык кассасында әбиләренең бер мең сум акчасы бар иде, ул шуңа туган көн әзерләде.

2001 елның 14 сентябре иде, Камилгә 10 яшь тулды. Әй, биш сәгать буена котырып та карадылар Камилнең классташлары. Араларында әбиләре бармы-юкмы – алар аны сизмәделәр дә бугай. Чөнки бүген аның үзенә дә 10 яшь иде. Җырладылар, биеделәр, сукыр тәкә, йөзек салыш, күзбәйләш уйнадылар, туйганчы көлделәр, арыдылар. Кунаклар соң гына таралышты, китәселәре килмәде – әти-әниләре килеп алдылар.

Камилнең ул кичтә йокысы килмәде. Инде күптән аерым, үзе генә йокласа да, әбисе янына килеп ятты.

- Әбием, миңа үзең турында сөйлә әле?!

- Мин бик арыдым , улым, - диде. Әйтерсең лә, бу көтеп алынган, бик тә кадерле бала ниндидер афәт, зур фаҗига якынлашуын сизә иде. Озак ятканнан соң әбисе:

- Улым, - диде акрын гына, - мин үзем турында китап язам. Язып бетереп чыгара алсам, мин аны “Көзге моң” дип атармын. Туганнан бирле минем тормышым сагыш-моң белән үтте. Көзге сары яфракларны, көзге урманны хәтерләтә.

- Ә үзең: “Көзләр миңа сине бүләк итте”, дия идең...

Өйдә соңгы төн иде бу. Йокладылармы икән, әллә юкмы икән?!

Иртән юлга җыендылар. Менделеев районына кайтып, укытучылар, авыл хуҗалыгында эшләүчеләр өчен 1 октябрь көненә концерт белән кайтырга сөйләшеп киләселәре бар иде. Бер уңайдан туганнарны, туган авылны да күрерләр, Чаллыга да кереп, урамнарны әйләнеп, күрәселәрне күреп чыгарлар.

Җырчы Илдус Сафин: “Яңа машина алдым, үзем алып кайтырмын”, - ди дә соң, юк, бу юлы үзләре генә кайтсыннар әле, 55 яшенә райондашлары бүләк иткән “Ока”га төялештеләр дә кайтып та киттеләр. Шундый тиз кайттылар, юллары да уңды, күрәсе кешеләрне дә күрделәр. “Кайтыгыз, көтәбез”, - дип калдылар.

Ә инде 2001 елның 16 сентябрендә дөньяга “Көзге моң” булып коточкыч хәбәр таралды. Чаллы-Казан юлында Мамадыштан ерак түгел Татарстанның һәм Каракалпакстанның халык, Руссиянең атказанган артисты, җырчы, милләтпәрвәр,

сәясәтче Вафирә Гыйззәтуллина утырган машина юл һәлакәтенә очрады. Вафирәне моргка, Камиләне бер, Камилне икенче больницага алып киттеләр.

* * *

Ул көнгә 4 ел үтеп китте. Вафирәнең мәетен башта Мамадышка алып киттеләр, аннан Казанга алып кайттылар. Ул инде тынычланып калган, әйтерсең,йокыга талган. Йөзе ап-ак, тыныч, бәхетле. Күрәсең, ул авыртулар сизәргә өлгермәгәндер. Инде менә 4 ел узгач, шул турыда курка-курка, үлгән кеше ничек матур булсын, дип әйтер дип, Камиләгә әйттем.

- Шулайдыр, - диде ул. – Мин өстебезгә ыжгырып килгән, барыбызны да сытып китәсе үлемне күрдем. Ул әле дә минем төшләремә ямьсез зур машина, котырган үгез, усал ата каз булып керә. Арага кочагын җәеп әни керә дә уянып китәм.

Төптән үк аягын кисәргә, дигән бу бала коточкыч авыртулар, әрнүләр, сызлаулар кичерде. Ярты ел Илизаров аппаратында ятты. Өйдә култык таякларына басты, йөрергә өйрәнде. Тора-бара урамга чыкты. Яшәргә кирәк иде.

- Тән ярасы берни түгел, гомерлек югалту авыр булды, - ди ул.

Камилә Гыйззәтуллина (ул әнисенең фамилиясен алды) 5 нче гимназия укучыларына музыка дәресләре бирә, фортепианода уйнарга өйрәтә.

Камил дә зур егет булып килә, 9 нчы класста укый инде. Әбисенең ягы баскан бугай. Ул да әдәбиятне, сәнгать, тарих, экиятләр, Тукайны, Муса Җәлилне ярата.

Вафирәнең мәетен филармониянең концерт залына куйганнар иде. Хушлашу бик тиз булды, алда озын, соңгы юл иде. Анысы да гади генә булмады: Казан-Чаллы юлы кеше белән тулган иде. Камай авылының тирә-ягын автобуслар, җиңел машиналар урап алган. Авылдагы һәр йорт капкасын ачып куйган. Димәк, аны туган авылында да һәр йорт үзенеке дип санаган.

Авыллары матур. Минем әле Бәдерниса апа, Мөхәммәтддин абзый исән чакта кунак булып кайтканым бар иде. Инде менә Вафирәне озата кайттык. Аның кабере Менделеев районының Камай авылында. Бөтен авыл озата чыккан. Казанда гына хушлашу бик тиз булды. Никтер ашыктыралар иде. Ә Камайда көтәләр. Зират буенда ике пар елый. Яшьләрен тыя алмыйлар, хәер, тыярга теләмиләр дә, кирәкми дә. Алар аның гомерлек якын дуслары, музыкантлар. “Кирам, әйдә Красноярга”, “Рамил, әйдә Ташкентка”, дисә, бер сәгатьтә әзерләнеп чыгып китәләр иде. Әлбәттә, болар халкыбызның яраткан, алыштыргысыз баянчыларыбыз Сатиев белән Курамша иде.

Вафирә юлларны, җырларны һәм кешеләрне, аның да әле бәрелгән-сугылганракларын күбрәк ярата иде. Күрәсең, без – аның тамашачылары, дуслары – аны шуның өчен дә яратканбыздыр.

## “Кешегә булышудан ләззәт таба иде...”

***Рамил КУРАМШИН ,Шәһри Казан, 25.01.2011 ел.***

Моннан ун ел элек Г.Камал театрында Татарстанның халык артисты Вафирә Гыйззәтуллинаның 55 яше тулуга багышланган кичә зур уңыш белән үткән иде. Ул кичәдә Вафирә бөтен җанын биреп, очып китәрдәй булып, шундый илһамланып җырлады ки, әйтерсең лә ул алдагы язмышын сизенгән диярсең... Чөнки берничә айдан, аяз көнне яшен суккандай, йөрәкләрне әрнетеп, Вафирәкәебез бу якты дөньядан бакый дөньяга китеп барды.



Без Вафирә белән Казан музыка училищесында бер курста укыдык: ул вокал бүлегендә, мин халык уен коралларында. Үзенең буй-сыны, чибәрлеге, чаялыгы, үткен теллелеге белән Вафирә башкалардан аерылып тора иде. Безнең курста гына түгел, бөтен училище күләмендә дә ул үзенә күрә бер лидер иде. Безне, училище студентларын, кайвакытта нинди дә булса бәйрәм йә башка чара уңаеннан төрле оешмаларга концерт куярга җибәрәләр иде. Ул елларда бит микрофонга җырлау дигән нәрсә юк. Вафирә, яшь кенә булуына карамастан, үзенең табигый тавышы һәм артистлыгы белән тамашачы күңелен бик тиз яулап ала иде. Программа буенча чыгышы тәмамланса да, көчле алкышлар белән аны кабат җырлаталар иде. Ә бит андый оешмаларда төрле милләт вәкилләре була. Училищеда укыган елларда ук Вафирә радиода язмалар эшли башлады, телевидениедән дә чыгышлары булгалый иде. Кыскача әйткәндә, шул елларда ук аның киләчәктә зур җырчы булачагы күренеп тора иде.

IV курста укый башлаган көннәрдә Вафирә, нишләптер, училищеда күренми башлады. Шунда безнең белән бер курста укучы Венера Гәрәевадан (ул хор дирижерлары әзерләү бүлегендә укый иде, соңыннан консерваторияне тәмамлап, озак еллар дәвамында Татар дәүләт җыр һәм бию ансамблендә баш хормейстер булып эшләде) шул хакта сораган идем, ул: «Син нәрсә, белмисеңмени? Аны бит III курстан соң консерваториягә укырга алганнар», – дип, мине гаҗәпкә калдырды. Гәрчә, бер караганда, гаҗәп тә түгел иде, чөнки Вафирәнең әзерлеге консерваториядә укыр өчен бик җиткән иде инде.

Вафирә консерваториядә укыганда кияүгә чыкты, кызы Камиләне үстерде һәм шуңа күрә укуы бераз тоткарланды. 1975 елда укуын тәмамлап, ул безгә, Г.Тукай исемендәге Татар дәүләт филармониясенә, эшкә килде. Гадәттә, яңа гына эшкә алынган җырчы башта «Фәләнев җитәкчелегендәге концерт бригадасы»нда «антураж» булып эшли башлый һәм күбесе шуннан артык үсә дә алмый, чөнки «бригада җитәкчесе» булу ул елларда бик зур мәртәбә санала иде. Аның өчен халык арасында киң танылу алган җырчы булуың мәҗбүри, артистлар телендә бу «сәхнәне тота алу» дип атала. Ә Вафирә бу башлангыч этапны үтеп тормады диярлек. Филармониягә килгән елдан ук ул үзе «бригадир» булды. 20 ел дәвамында шунда эшләп, ул зур уңышларга ирешә, гәрчә, аның иҗат юлы гел чәчәкләр белән генә түшәлгән иде, дип әйтү бик үк дөрес булмас иде.

Вафирә эшли башлаган елның октябрь аенда без филармония артистларының «зур концерт»лары белән Урал шәһәрләренә гастрольгә киттек. Анда җырчылардан Илһам Шакиров, Әлфия Авзалова, Габдулла Рәхимкулов һәм Вафирә бар иде. Шундый күренекле җырчылар когортасы янында да Вафирә һич тә югалып калмады, аның чыгышларын да тамашачы бик җылы кабул итте. Ул елларда мин И.Шакиров бригадасында эшли идем. Ләкин менә шундый «зур концерт»ларда, радио-телевидениедә миңа Вафирәгә баянда уйнарга туры килгәли иде. Ә инде 1990 елдан алып 1994 елның көзенә кадәр (ни аяныч, шулчакта

көтмәгәндә-уйламаганда филармониянең эстрада бүлеген тараттылар) без Вафирә җитәкчелегендәге бригадада бергә эшләдек.

1985 елда үзгәртеп корулар чоры башлангач, Вафирәнең элекке елларда ук шәйләнгән милләтпәрвәрлеге аеруча калкып чыкты. Ул бу форсатка ихластан шатланып, «атаң улы гына булма, Ватан улы була бел» дигәндәй, Татарстаныбызның мөстәкыйльлеге өчен көрәшкә, милли хәрәкәткә кушылып китте. Әлеге мәсьәләдә без Вафирә белән тулысынча фикердәшләр идек, шуңа күрә аның бу өлкәдәге эшчәнлеге дә минем күз алдымда булды, дип әйтә алам. Аның акылы, энергиясе, үзе әйтмешли, җыр кысаларына гына сыймыйча, халкыбызның азатлыгы өчен сәяси көрәшкә дә җитә иде. Милли хәрәкәтнең иң көчле елларында (1990-1993) төрле митингларда Вафирә үзенең ялкынлы чыгышларыннан соң, хәтта салкын җилле, яңгырлы көз көннәрендә «Ком бураны» дигән җырны җырлап җибәрә иде. Юк, бу аның, кайбер «акыллы башлар» уйлавынча, ниндидер популярлык, дан-шөһрәт артыннан кууы түгел (алары Вафирәдә болай да җитәрлек иде), ә бары тик үз халкы өчен утка-суга керергә әзер булган фидакарьлек гамәле генә иде.

Миңа озак еллар дәвамында күп җырчыларга уйнарга туры килде, әмма җыр-моңнары белән генә түгел, ә акыллы, тирән мәгънәле сүзләре белән дә тамашачының күңеленә үтеп кереп, аның милли тойгыларын, милли горурлыгын уята белгән ике җырчыны гына атый алам: аның берсе мәшһүр Илһам Шакиров булса, икенчесе Вафирә иде.

1990 елның март аенда без, берничә артист, андагы Татар иҗтимагый үзәге чакыруы буенча Латвия башкаласы Рига шәһәренә бардык. Бу вакытта Латвия СССРдан аерылып чыгу алдында тора иде. Андагы милләттәшләребез безгә «тагын килгәндә инде чит илгә килерсез» дигәннәр иде һәм, чынлап та, берничә айдан Латвия бәйсез дәүләт булды. Шулай беркөнне Вафирә белән урам буйлап барганда, бер латыш кешесе белән сөйләшеп киттек. Безнең Татарстаннан килгән татарлар икәнлегебезне белгәч, ул тагын да җанлана төште. «Явызлык империясе»нең рус булмаган халыкларга карата эшләнгән төрле җәбер-золымнары турында байтак сөйләшеп тордык, чөнки милли аңы югары булган бу халык вәкиле белән сөйләшеп тору безгә бик кызык иде. Саубуллашканда ул: «Мондый кызлары булган халык югалмаячак», – дип, Вафирәнең сәяси зирәклегенә соклануын белдерде. Ригада без 4 көн булдык. Соңгы көнне милләттәшләребез безнең өчен мәҗлес оештырды. Анда Татар иҗтимагый үзәге активистлары һәм Ригада яшәүче күренекле татарлар җыелган иде. Мәҗлеснең урта бер җирендә: «Әйдә, Рамил, «Кара урман»ны җырлап, милләттәшләребезне бер моңландырып ал әле», – дип, Вафирә минем ике аякны бер итеккә тыгып куймасынмы? Чөнки ул чакта бу җырны халык алдында түгел, хәтта үз-үземә дә җырлап караганым юк иде әле. Ләкин Вафирә акланып торырга урын калдырмаган иде – аның бу сүзләрен табында утыручылар да ишетте. Мин, Аллага тапшырып, җырлый башладым һәм... Вафирәнең җиңел кулы белән җырлый башлаган җырны, җае чыккан саен, бүгенге көнгә кадәр җырлавымны дәвам итәм.

Латин телендә «Кеше дөньяга кешегә булышыр өчен килә» дигән гыйбарә бар. Вафирә дөньяда нәкъ менә шушы мәсләк белән яшәде. Ул кешегә булышудан ниндидер бер ләззәт таба иде. Аның исеме дә җисеменә бик тәңгәл килгән: «Вафирә» гарәпчә «киң күңелле» дигән сүз бит. Бу фикеремә дәлил итеп, аның шәхсән үземә карата эшләгән миһербанлы бер гамәлен искә төшерү дә җитәр дип

уйлыйм. 1981 елның апрель ае иде. Беркөнне шулай филармониядә очрашкач, Вафирә миңа: «Рамил, тиздән син фатир алачаксың. Миңа ике бүлмәлене бирәләр, ә сиңа үземнең бер бүлмәле фатирымны калдырырга сөйләштем», – дип, мине шаккатырмасынмы! Һәм, чынлап та, июнь башында гастрольдән кайтып, филармониягә барган идем, кулыма ордер тоттырдылар. 34 яшен тутырып килүче һәм шул гомернең яртысын тулай торакларда яшәп үткәргән кешегә моның нинди шатлык булуын аңлатып торасы юк. Соңыннан Вафирә тагын шунысын да сөйләде: аңа бу ниятен тормышка ашыру өчен филармония җитәкчеләре белән бәхәсләшергә, төрле дәлилләр китерергә туры килгән. Һәм барыбер үз дигәненә ирешкән. Монда иң гаҗәбе шул, мин бит аңа: «Фатир алырга булыша алмассыңмы?» – дип, авызымны да ачканым булмады.



җырчының грампластинкасы булса, бу инде аның өчен зур к… Ә грампластинкага язылу Мәдәният министрлыгы рөхсәте б…, һәм бу «рөхсәт» бөтен кешегә дә тәтеми дә иде. Сүз, ә…ында, филармониядә эшләүче профессиональ җырчылар т…генә ул теләсә кем кассета, диск чыгара ала, акча түләсә, у… дә языла ала). Бервакыт ничектер уйланып киттем дә Б… тәҗрибәле, халык артисты исемен йөрткән абруйлы җырчы. А…егең дә бар, сүзең дә үтә. Мин шуңа гаҗәпләнәм: нишләп, бүгенге көнгә кадәр синең бер генә грампластинкаң да юк?» – дип сорау бирдем. Ул исә: «Тәкъдим итүче булмады, ә үзем артыннан йөрмәдем. Үзең беләсең, минем әнә радиода да, телевидениедә дә язмаларым бар, миңа шул җиткән», – дип кенә җаваплады. Әйе шул, кешеләргә яхшылык эшләргә ашкынып торса да, үзе өчен ул алай әрсезләнә белмәде. Зур сәнгать әһелләренә хас тыйнаклык дигән нәрсә аңа да хас иде.

2001 елның июнь аенда Татар иҗтимагый үзәге әгъзасы, күренекле юрист Гаял Мортазинга 60 яшь тулу уңаеннан, Тукай клубында кичә булды. Шул кичәдә Вафирә, Гаял әфәндене котлап, берничә җыр башкарды. Андый кичәләр, гадәттә, халкыбызның рәсми булмаган гимнына әйләнгән «Туган тел» җырын җырлау белән тәмамлана бит. Шушы вакыт килеп җиткәч, Вафирә миңа, кинәт кенә: «Әйдә, Рамил, «Туган тел»не икәү җырлыйбыз», – дигәч, мин: «Сиңа каршы килеп булмый инде, әйдә киттек», – дип, сәхнәгә чыгып киттек. Үзебез җырлыйбыз, ә үзебез, гаҗәпләнеп, бер-беребезгә карашып алабыз. Ни гаҗәп: безнең тавышлар туры килә икән ләбаса, әйтерсең лә гомер буе бергә җырлап йөргәнбез. Сәхнә артына чыккач, Вафирә: «И-и, Рамил, күпме бергә эшләп, шуны белми йөргәнбез икән. Соң булса да, уң булсын, әйдә, берничә дуэт әзерлибез дә радиога язылабыз һәм концертларда да җырларбыз», – дип, киләчәккә планнар да кора башлаган иде, ләкин... бу безнең соңгы очрашуыбыз булган икән...

Вафирә Гыйззәтуллина турындагы истәлекләрне бер газета мәкаләсе кысасына гына сыйдырып бетереп булмый, әлбәттә. 90 нчы еллар башында күренекле язучыбыз Аяз Гыйләҗев бер интервьюсында безнең өчен шигарь булырлык шундый фикер әйткән иде: «Мин бүгенге көн әдәбият-сәнгать әсәрләренә бәяне «Бу әсәр татар халкын саклап калуда нинди урын тотар?» дигән күзлектән чыгып кына бирә алам». Вафирәнең иҗаты да, гомумән, бөтен гомере дә нәкъ менә шушы изге эшкә – халкыбызны милләт буларак саклап калуга багышланган иде.

Исән булса, февраль аенда Вафирәкәебезгә 65 яшь тулган булыр иде. Бу язмам аның якты рухына дога булып ирешсен иде.

## “Бөтенесе Вафирә түгел...”

***Гөлинә Гыймадова.***

Вафирә Гыйззәтуллина – Рамил Курамшинның курсташы. Дуслары аның зур җырчы булачагын шул елларда ук сизенә. Чөнки ул үткенлеге, чаялыгы, табигый матурлыгы белән бүтәннәрдән аерылып тора.

- 90 нчы елларда аның бу сыйфатлары тагын да яктырак булып калкып чыкты. Урамнарда “Ком бураны” дигән инкыйлаб җырын җырлау аның өчен берни түгел иде, - дип искә ала Рамил абый.

- Вафирә ханым концертның урта бер өлешендә тамашачы белән халкыбызның милли язмышын, суверинитет турында сөйләшеп алуны гадәткә кертте. Ул сөйләгәндә залда чебен очкан тавыш ишетелерлек тынлык урнаша иде. Артистка тәҗрибәле психолог кебек халыкның милли кылларына кагыла белде. Тамашачы, гадәттә, аның сүзен хуплап көчле алкышларга күмә иде. Мин исә, баянымны күтәреп аның янында басып торганда, юк шул, бөтен артист Вафирә була алмый, дип үкенә идем.

## Вафирә Гыйззәтуллина кызы Камилә белән әңгәмә.

***Гөлинә ХИСАМЕТДИНОВА, “ Ватаным Татарстан”, 2012 ел.***



Әни тынгысыз һәм эзләнүчән иде. Россиянең атказанган, Татарстанның һәм Каракалпакстанның халык артисты Вафирә Гыйззәтуллинаны кызы Камилә әнә шулай искә ала.

Килеш-килбәте белән дә, холкы белән дә әнисен хәтерләтә ул. Әйтерсең лә, аннан сүнмәс маякны алып калган да, аны халык күңеленә илтеп җиткерүне максат итеп куйган. Ләкин ысуллары гына үзгәрәк. Вафирә сәхнә тотса, Камилә сәхнә артын сайлаган. Юкса тавышы нәкъ әнисенекедәй чишмә сыман челтери, ә аһәңе еракларга китә. Әмма нидер сәхнәгә атларга комачаулый, чабудан тота. Шунысына шик юк: Камилә Гыйззәтуллина әнисенең исеме халык хәтереннән җуелмасын өчен кулыннан килгәннең барысын да эшли. Билгеле, бер хатын-кыз күпме генә эш башкара ала икән? Шулай да, көне-төне таптаган бусагалардан буш кул белән чыгулар ешаеп китсә дә, башлаган юлыннан туктап кала торганнардан түгел ул.

**– Камилә ханым, әниегезнең исемен мәңгеләштерүдә бөтен көчегезне сарыф итүегезне беләбез. Бу уңайдан бүген нинди уй-фикерләр белән яшисез?**

– Мин Казан шәһәре Вахитов районының 5нче лицее каршындагы 26нчы музыка мәктәбендә хор һәм вокал дәресләрен алып барам. Шөкер, музыка мәктәбе директоры да, лицей җитәкчесе дә миңа һәрвакыт хәерхаһлы булдылар. Бүген без музыка мәктәбенә әнинең исемен бирү артыннан йөрибез. Шулай ук "Сүнмәс йолдыз" дигән проект та старт алды. Аның буенча диск чыгару, концерт оештыру, музей ачу каралган. Бүгенге көндә беренче ике шарт үтәлгән, инде музей ачыласы көннәр дә санаулы гына калды. Узган елны әнигә 65 яшь тулган булыр иде. Мин бу датаны билгеләп үтмичә кала алмадым. Әни турында кино төшердек, ул филармониядә узган искә алу кичәсендә тәкъдим ителде. Әнинең чордашлары – Зилә Сөнгатуллина, Римма Ибраһимова – һәрбарчасы ул көнне бушка эшләделәр, рәхмәт аларга. Шагыйрь, депутат Разил Вәлиев, Камал театры директоры Шамил Закиров, артист Зөлфирә Зарипова, башка бик күпләр матур хатирәләре белән уртаклаштылар – аларга хөрмәтем чиксез. Шунысын да җиткерик, узган ел

Вафирә Гыйззәтуллина исемендәге балалар һәм өлкәннәр төбәкара конкурсын башлап җибәргән идек, быел да шул конкурска әзерлек бара.

**– Моңы белән дә, туры сүзе белән дә халыкка хезмәт иткән, гастроль юллары Карпаттан Чукоткага кадәр сузылган җырчыны, белмим, кызы гына кайгыртырга тиеш түгелдер бит инде? Мәдәният министрлыгы, ул эшләгән филармония нинди ярдәм күрсәтә?**

– Мәдәният министрлыгына әни яшәгән йортта (Татарстан урамы, 7) мемориаль такта ачасы иде дип мөрәҗәгать иткән идем. Бу йортта яшәүчеләр барысы да шуны көтә, Рөстәм Яхин, Хәйдәр Бигичев элмә такталары янында Вафирә исеме дә уелырга тиеш, диләр. Министрлыктан бик күп кәгазь килде. Аның буенча мин бу эшне үзем башкарырга тиеш икәнлегемне аңладым... Ләкин ничек? Диск дигәннән, аны чыгару үзе бер могҗиза булды. "Кара-каршы" тапшыруының бер чыгарылышы әнигә багышланган иде. Миннән алып баручылар, ни хәлләрегез бар, дип сорадылар. Мин инде әнинең җырларын туплап диск та чыгарып булмый дип сөйли башлаган идем, филармония директоры Кадим Нуруллин дискын үзем чыгарам дип игълан итте. Мең данә диск "Аксу" студиясендә чыкты. Ләкин ул сату өчен түгел, теләгән кеше аны ала алмый. Янәшәбездәге мәчет тә бер урамга әни исемен кушу, элмә такта булдыру кебек эшләрдә ярдәм итүләре турында язма документ биргәннәр иде. Күрәсең, әле вәгъдәләре җитмәгән.

**– Сезнең җитәкчелектәге "Гүзәлем" ансамбле дә Вафирә Гыйззәтуллина репертуарын халыкка җиткерә бит әле. Өч тавышка акапеллага башкарган "Кызарып кояш баткан чакта" (И. Шәмсетдинов муз., М. Максуд сүз.,) җырын күз яшьләрсез тыңлап та булмый.**

– "Гүзәлем" ансамбленең үргә күтәрелүе Сара Садыйкова исемендәге бәйгедән соң башланды, дисәк хата булмас, мөгаен. Без анда беренче урынны алдык. Аннан Екатеринбургта, Новгородта бөтенроссия конкурсларында, күп кенә илкүләм бәйгеләрдә җиңүләр. Әни эстрадада чүп җырларга каршы иде. Без дә балаларга яшьтән халык җырларын, профессиональ композиторлар җырларын өйрәтәбез. Вокалистларның җырлау нормасы – көнгә дүрт сәгать. Ә мин балалар белән иртәнге сигездән кичке сигезгә кадәр җырлыйм. Шундый кеше инде мин, башкача булдыра алмыйм.

**– Шулай да әниегез кебек җырчы булып китмәвегез кызганыч.**

– Аның юлын кечкенәдән бергәләп үткәнгә эстраданы сайлыйсым килмәде, ахры. Әлбәттә, бик кызыклы, гыйбрәтле тормыш. 1978 елда Эстониядә РСФСРның әдәбият һәм сәнгать көннәрендә Татарстаннан Нәҗип Җиһанов белән Вафирә Гыйззәтуллина катнашты. Пугачева, Хазановлар белән бергә. Менә шулай өйгә кайтып та кермәде инде ул. Кама ярларында туып үскән гап-гади кыз моңы белән Германия, Куба, Австрия, АКШ тамашачысын әсир итте. Сәнгать белән яшәде ул. Тик менә үз вакытында кассета чыгарырга вакыты җитмәде. Теләге дә юк иде. Мин бу турыда сүз кузгатсам, мин кассета җырчысы түгел дип әйтте. Чын талант ияләренең гомере кыска була, күрәсең. Сизенгәнмедер, кыска гына гомере эчендә бик күп эшләр башкарырга теләде. Концерт алдыннан халыкны уятырга теләп сөйләүләр, мәйданга чыгу, трамвай юлына аркылы төшүләр әнә шуннан. Аның милләт турында уйланулары, уй-тойгылары шигырьләрендә, публицистик язмаларында да ачык чагыла.

**– Берзаман филармониядә эстрада бүлеге кыскартылгач, Вафирә Гыйззәтуллина һәм башка бик күп җырчылар урамда калды. Шул чорга әйләнеп кайтыйк әле.**

– Ул вакытта мин дә филармониядә эшли идем. Әнинең кыскартылганын белгәч, эштән азат итүләрен сорап гариза яздым. Сине кыскартмыйлар бит, ник китәсең, диделәр. Ничек инде мин әнине санламаган, кадерсезләгән оешмада эшли алыйм? Әни югалып кала торганнардан түгел. Вафирә исеме "киң күңелле" дигәнне аңлата бит. Ул өйдә төрле композитор, язучылар белән аралашты. Кем белән генә аралашса да, милләт язмышы өчен борчылды. Тик аның өчен борчылдылармы соң? Бар иде шундый заманнар, безне туендырыр өчен ул концерт күлмәкләрен чыгарып сатарга мәҗбүр булды. Һәлакәткә очраган көнне дә без акча бетеп районга концерт куярга чыгып киткән идек.

**– Мәйданда Россиянең атказанган җырчысы дигән таныклыкны яндыру эзсез узмагандыр.**

– Юк, билгеле. Өйгә милиция килеп үгетләде дә, янады да. Ә Каракалпакстанда халык җырчысы исемен биреп, мәдәният министры булырга тәкъдим ясадылар. Ул туган як сандугачы иде шул. Халыктан сайланып депутат булырга теләде. Үткәрмәделәр, билгеле, беренчедән, акчасы юк, икенчедән, теле озын.

**– Бүген Вафирә Гыйззәтуллина дигән исем халык хәтерендәме икән?**

– Мин халык хәтерендәдер дип өметләнәм. Ул бит халык дип яшәде, иҗат итте. Андый җырчы, андый тавыш, андый шәхес башка юк бит ул. Мин моны әни булганга гына әйтмим.

Соңгы елларда аның яшисе килмәде. Дөнья кысаларын тарсындымы, күпме генә өзгәләнсә дә, хәтерсезлек корбаны булу күз алдына килдеме – белмим. Еллар узган саен тормышның тизлеге арта бара дия иде. Мин дә шулай уйлыйм. Әнинең гомер юлын кабатлаган кебек үк, музыка училищесын тәмамладым. Унҗиде ел эшләгәннән соң университетның музыка факультетында укып йөрешем. Мин анда староста да әле. Камил улым кебек үк, студент мин бүген.

**– Камилә, синең әтиең Лариса дигән исем кушкан бугай.**

– Лариса Джураева идем мин. Әни минем белән торасың бит, күч минем фамилиягә дигәч, аның фамилиясен алдым. Камилне тапкач исә, егерме биш яшемдә, мулла азан әйтеп Камилә исемен кушты.

## Тагын Вафирә турында...

***ГӨЛИНӘ ХИСАМЕТДИНОВА, "Ватаным Татарстан", 2012 ел.***

Гомере вакытсыз өзелгән сүнмәс йолдыз – Вафирә Гыйззәтуллинаның исеме Казанда мәңгеләштерелгәнме? Кызганыч, бу сорауга уңай җавап биреп булмый. Әйтерсең лә, ул Казанның Татарстан урамындагы йортта яшәмәгән – чөнки бу йортта аның турында бернинди дә элмә такта юк. Җырчы музыка училищесында да укымаган – чөнки училище сайтында аның турында бер мәгълүмат та табып булмады. Юкса бу уку йортында шундый мәшһүр җырчының белем алуы аңа, һичшиксез, популярлык кына китерер иде. Соңгы өмет – Муса Җәлил исемендәге опера һәм балет театры сайтын ачам. Анда да бәлки фотосы бардыр дигән өмет чәлпәрәмә килә.

Ләкин Вафирә Гыйззәтуллина яшәмәгән, эшләмәгән, җырламаган дип әйтергә кем генә җөрьәт итәр икән? Аның репертуарындагы җырлар әле дә яңгырый, батырлыгы, горурлыгы хакындагы сүзләр телдән-телгә күчә.

Ялгышам икән, Казанда Вафирә Гыйззәтуллина рухы яшәгән бер бәләкәй генә утрау бар. Бу – Казан шәһәренең 5нче лицее каршындагы 26нчы музыка мәктәбе. Монда җырчының кызы Камилә Гыйззәтуллина балаларга әнисенең репертуарын өйрәтә, аннан калган ядкарьләр белән бүлешә.

Камиләнең әнисе исемен кире кайтару юлында ничек бәргәләнгәнен күргән музыка мәктәбе директоры Галина Голубева аңа ярдәм кулы суза. Республика күләмендә эш башкарып булмый икән, әйдә балалар күңеленә юл ачыйк, ди ул. Шулай итеп, бу мәктәптә ел саен сентябрь аенда Вафирә Гыйззәтуллинаны искә алу кичәсе үткәрелә башлый. Мәктәп шәһәр мәгариф бүлегендә теләктәшлек табып, узган ел Вафирә Гыйззәтуллина исемендәге “Күңелдә мәңге яз” дигән балалар, яшүсмерләр, өлкән яшьтәгеләр өчен ачык төбәкара фестиваль-конкурс оештырып җибәрә. Быел да мәктәп мәгариф бүлегенең ярдәменә өмет итә. Чөнки җырчы исемен мәңгеләштерүгә ярдәм итүче бердәнбер оешма шушы икән.

“Менә шулай, безнең коллектив Вафирә Гыйззәтуллинаның онытылган исемен кире халыкка кайтара. Аның җырлары балаларның йөрәкләрендә саклана”, – ди Галина Голубева.

Музыка мәктәбе Вафирә Гыйззәтуллина җырларында Регина Вәлиеваны тәрбияләп үстерде. Халыкара конкурсларда лауреат исемен яулаган бу яшь җырчы шушы мәктәп укытучысы, филармониянең алыштыргысыз солисткасы да. 26нчы музыка мәктәбе “Гөлләрем” ансамбле белән дә горурлана. Кызлар мәктәп данын халыкара конкурсларда яклады. Узган елны шундый конкурсларның берсеннән алтын медаль белән кайтты. “Россия” каналыннан бара торган “Битва хоров” тапшыруында да шушы мәктәпне тәмамлаучылар ярыша икән. Менә нинди мәктәп коллективы икән бу! Аларга үткәннәрне кадерләп саклаулар, татар сандугачының исемен онытырга ирек бирмәүләр ярдәм итә торгандыр да әле.

Бу атнада 26нчы мәктәп тагын бер күркәм гамәле белән сокландырды. Ул үзенең бер бүлмәсендә Вафирә Гыйззәтуллина музеен оештырып җибәрде. 5нче лицей директоры Гүзәл Рәхмәтуллина: “Бу эшебез беренче адым итеп кабул ителсен иде. Алга таба Вафирә Гыйззәтуллина исемен мәңгеләштерүдә республикадан да зур адымнар көтеп калабыз”, – диде.

Музей экспонатларыннан күренгәнчә, Вафирә кая гына чыгыш ясаса да, халык мәхәббәтен яулап кайткан. Каракалпакстанда бүләк ителгән җилән, түбәтәй (монда 1978 елда аңа хәтта мәдәният министры булып калырга да тәкъдим итәләр), Менделеев районы халкыннан бизәкләп эшләнгән самовар, Башкортстан балчыларыннан мичкә... Барысы да имзалы, язулы. Вафирә Гыйззәтуллинаның дипломнары, аның китабы... Баксаң, җырчы үз куллары белән “Тормыш китабы”н яза башлаган икән. Көндәлек рәвешендәге кульязма-китап җырчының дөньяга, сәяси “уеннар”га мөнәсәбәте хакында сөйли... Шушы кульязманы күрергә килгән җырчының дусты, Татарстанның теннис буенча федерация советы директоры Рәмзия Нуриева белән аның ничек итеп депутат булырга йөргән көннәрен искә алабыз. Билгеле, анда җырчы түгел, Сергей Шашурин җиңә... Рәмзия ханым Вафирәне бары тик ягымлы, көләч, олысына-кечесенә ярдәм итәргә ашкынган кеше итеп хәтерли.

Музейда тагын бер кызыклы ядкарь бар. Бу – билгесез рәссам ясаган портрет. Камилә: “Көннәрдән бер көнне телефон шалтырады. Без Болак буендагы чүплектә Вафирә Гыйззәтуллинаның портретын таптык. Кирәк булса, килеп алыгыз, дип шалтыраттылар”, – дип искә ала. Менә шундый серле табылдыклар, кызык та, кызганыч та хәлләргә дучар булган җырчы ул Вафирә...

Камиләдән, һич югы элмә такта ясату турында вәгъдәләр ишетелмиме, дип сорамыйча булдыра алмадым. Ул исә: "Мине мәдәният министрына кертмиләр. Ничә бардым, ул буш түгел, диләр. Безгә иң яхшысы – хат языгыз, дип кире бордылар. Минем исә министр белән күзгә-күз карап сөйләшәсем килә. Такта дип авыз ачсам, смета сорыйлар. Мин ничек төзим аны, хисапчы түгелмен бит", – дип иңнәрен җыера. Вафирә Гыйззәтуллина тирәсендәге менә шундый аңлашылмаучылыклар килгән һәр кешене борчуга салды. Кайда инде дискын чыгарыйк, урамга исемен кушыйк дип авыз ачу?

Җырчының үз куллары белән язган "Тормыш китабы"нда киләчәк буынга да теләкләр бар.

### "Чын күңелдән җырлыйм, күңел өчен язам..."

***Роберт Нәбиуллин, "Менделеев яңалыклары" 2014, октябрь***

**Шушы көннәрдә композитор һәм автор-башкаручы Роберт Нәбиуллин 70 яшьлек юбилеен билгеләде. Аның сәнгатькә юлы сикәлтәле була, вакыйгалар агышы танылган артист булырга комачаулый, яки, Роберт Нәбиуллович үзе әйткәнчә, язмыш башкача хәл итә... Юбилее алдыннан ул корреспондент Рәхилә Мирзаянованың сорауларына җавап бирде.**

**- Роберт ага, сезгә зур иҗат потенциалы каян килгән? Инструментларда уйныйсыз, көйләр һәм шигырьләр язасыз, җырлыйсыз.**

- Иң беренче чиратта әниемә рәхмәтлемен. Мәдрәсәдә ике генә ел укуына карамастан, төрек төркемендәге җиде телдә иркен аралашты, авылда абыстай булды. Моңлы тавышы белән Коръән сүрәләрен укыганда, кешеләр елыйлар иде. Күп балалы гаиләдә үстем, кечкенәдән сәнгатькә тартылдым. Мәктәптә спектакльләрдә катнаштым, гармунда уйнарга өйрәндем. Зур сәхнәләрне буйсындыру турында хыялландым. Әни планнарымны хупламады: мин, көче ташып торган егет, гаиләгә ярдәм итәр өчен, эшләргә тиеш идем.

Урта белем турында аттестат алгач, юл чатында калдым: кая барырга? Җәйгә дустым Әхәт белән колхоз фермасына урнаштык. Көн саен иртәнге өчтә Камай заводына сөт ташыйбыз. Беркөнне чишмә янында туктадык. Мин битемне юдым, су эчәргә иелдем. Шунда миңа чүмеч суздылар. Күтәрелеп карадым...һәм аның коңгырт күзләре әсирлегенә төштем. Зәңгәргә ак борчаклар төшкән гади ситсы күлмәк кигән кыз образы мине гомерем буе эзәрлекләде.

**- Бу очрашу язмышыгызны хәл иттеме?**

- Әйе. Таныш түгел кыз Вафирә Гыйззәтуллина булып чыкты. Аның киңәше буенча Алабуга мәдәният-агарту училищесына баян классына кердем, ләкин тәмамлый алмадым – армиягә повестка килде. Сөеклем белән аерылышканда, безнең "Вәгъдә" җырын һәр кичне җырлаячакмын дип ант иттем. Ул гади генә җавап бирде: "Көтәрмен". Өч ел Германиядә ракета гаскәрләрендә булганда, төрле милләтле хезмәттәшләрем җырны яттан беләләр иде.

**-Демобилизацияләнгәннән соң үзегезне музыкага багышларга һәм сөеклегез белән планнар төзергә булдыгыз?**

-Кызганычка каршы, очрашуыбыз киноларда күрсәтелгәнчә һәм романнарда язылганча үтмәде. Вафирә инде популяр һәм ихтыяҗлы артист иде. Мин Алабуга училищесын тәмамлый алмадым, башкалага киттем. Филармониядә эшләдем, концертлар алып бардым. Укуымны дәвам итү өчен, Казан пединститутының музыка факультетына кердем. Һәм богема тормышы өермәсенә эләктем:

гастрольләр, концертлар, алкышлар, дан... Сәяхәтләремнең берсендә коточкыч авариягә эләктем.

**- Бәхетсезлек очрагы тормышыгызны үзгәрткәндер?**

- Бер ел диярлек больницаларда дәваландым, мине яңадан җыйдылар дисәң дә була. Уйланыр өчен вакыт күп иде. Больницадан туп-туры туган авылым Тойгуҗага кайтып киттем. Өйдә бит стеналар да ярдәм итә. Җан яралары озак төзәлде. Каләмгә тотынмадым, тальяным шкафта тузан җыеп ятты. Һәм аны – минем Вафирәмне онытырга тырыштым.

**-Хәзер сез иҗат итеп яшисез, район чараларында актив катнашасыз.**

-Вафирә Гыйззәтуллинаның фаҗигале үлеменнән соң бер нәрсәне аңладым: ул минем хәрәкәтсезлекне хупламас иде. Юбилеем алдыннан икенче дискымны яздырдым, анда сигез яңа композиция керде. Серенада-сагыну минем музама багышланган. Шулай ук баян һәм халык инструментлары өчен “Җиңү сулышы” дигән концерт-композиция яздым. Шигырьләр җыентыгым тәмамлану алдында.

Ислам кануннары буенча яшәргә тырышам, һәр көнгә шатланам һәм Ходайга рәхмәт әйтәм. Иҗат өчен күп тә кирәкми дип уйлыйм, илһам чыганагын авылымнан, аның урман-кырларыннан, гади кешеләрдән алам. Мин җырларымны чын күңелдән башкарам, ә шигырьләремне күңел өчен язам.

## “Без хәтерсез халыкмы?..”

***Гөлинә Гыймадова, “Ватаным Татарстан”, 2015 ел.***

Узган елны Сираевлар гаиләсеннән борчулы хат алган идек. Менделеев районы Камай авылы зиратының ташландык хәлдә булуы аларны кулга каләм алырга мәҗбүр иткән. Без авыл беткәндер, юкса халык зиратны ташламас иде дип, юлга чыктык. Нәтиҗәдә “Без хәтерсез халыкмы?” дигән язма чыкты.

Камайда хәтер яши, күңел күзе тоныкланмаган

Әлеге җыйнак кына авыл җырчы сандугачыбыз Вафирә Гыйззәтуллинаны, шагыйрь, “Социалистик Татарстан” (хәзерге “Ватаным Татарстан”) газетасы журналисты Дифгать Сирайны, артистлар – Рәмзия Зиннәтуллина, Камил Гыйльмуллин һәм башка шәхесләрне биргән. Аның ташландык хәлдә булуына күңел ышанмаган иде.

Бер ел элек исә зират безне урман кебек шаулап каршы алды. Әмма анда чистарту эшләре башланган, бик күп карт агачлар киселгән иде инде. Мәңгелек йорт коймасыз калган, чөнки күптән түгел генә авыл җирле үзидарәсе дилбегәсен үз кулына алган Илнар Ахунҗанов зиратны өр-яңадан әйләндереп алырга исәпләгән. Зират – хәтер, хәтер бетсә, авыл да бетә, дип каршы алган иде ул. Билгеле, мондый зур эш атна-ун көн эчендә генә башкарылып чыга алмый. Аның өстенә башка мәшәкатьләре чыгып тора. Җитәкче алдына авылны юллы итү, су торбаларын алмаштыру, клуб һәм башка биналарны яңарту яки яңадан салу проблемалары да килеп баса. Шулай булса да ул безне, зират тәртипкә киләчәк, үзем башлап йөрим, дип ышандырып озаткан иде.

Күптән түгел редакциягә Дифгать Сирайның хатыны Зәмфирә апа килеп керде. Сиксән яшьлек карчыкны олы шатлык йөртә икән. Камай авылында булып, андагы үзгәрешләрдән күңеле тулып йөргән көннәре. Зәмфирә апа сөйләп биргәч, җирле үзидарәгә дә шалтыраттык. Илнар әфәнде, телефоннан әйткән белән генә чикләнмичә, редакциягә дә килеп китте. Авылда башкарылган эшләрнең фотоларын да алып килгән. Камай күзгә күренеп үзгәргән икән.

Баксаң, Зәмфирә апа зиратны төзәтүдә иганәчеләрнең берсе булган.

– Авыл халкы да, читтә яшәүче авылдашларыбыз да булышты. Камай сайлау округыннан Менделеев район советы депутаты Назыйм Әхмәтов төзелеш материаллары белән ярдәм итте. Зиратка сайдинг койма тотылды. Инде җеназа йортын ясыйсыбыз калды. Язга, Сабантуйга кадәр эшләп бетерәбез, Алла боерса, – диде башлык.

Илнар авылга моннан берничә ел элек кайткан, ә эшләре кайберәүләр гомер буе эшләгәннән күбрәк. Элек Менделеевскидагы Карпов исемендәге химзаводта участок җитәкчесе булган. Хисабыннан шуны белдек: авылда грунт юллар калмаган икән инде. Дифгать Сирай исемендәге урам асфальтлы, башка урам юлларына таш түшәлгән. Яңа кафе ачып җибәргәннәр, күп функцияле үзәк ачылган. Анысына Вафирә Гыйззәтуллина исемен кушканнар. Кызы Камилә ханым район башлыгына авыл клубына әнием исемен кушсыннар иде дип хат язган булган икән. Җыенда шул хат укылган, халык бу тәкъдимне бердәм хуплаган.

Авыл белән бәйле тагын бер гыйбрәтле вакыйганы искә төшерик әле. Камай халкы гомер-гомергә чишмә юлын онытмаган. Әмма берзаман чишмә корыган. Картлар, авылны агач баса дип тирәсендәге тупыл-тирәкләрне кистегез, бу бәла – шуннан, дигәннәр. Илнар белгечләр белән сөйләшкәч, моның чыннан да шулай булуын ачыклаган. Агач тамырлары чишмә өчен үзенә күрә насос ролен үтиләр икән. Җитәкче узган елны ул чишмә юлын табачакбыз дип әйткән иде. Вәгъдәсендә торган. Су юлын эзләп табып, чишмә күзен ачканнар. Тирә-юнен махсус проект белән таштан ясаганнар. Карап туйгысыз ял урынына әйләнгән.

Камай яши. Гөрлисе көннәре алда. Чөнки монда хәтер яши, күңел күзе тоныкланмаган. Баш исемгә куелган сорауга бу очракта кистереп юк дип җавап бирергә була.

## “Вафирә”

***Наилә Миннәхмәтова, “Саумы тормыш”, 2015 ел.***

Вафирә Гыйззәтуллинага мәрсия

*Гомер озынлыгы яшәгән еллар белән үлчәнми,*
*башкарган эшләр белән үлчәнә.*

Вафирә Гыйззәтуллина – минем укучым. Гел “5”легә генә укыды. Зирәк, булдыклы, эшчән, сәләтле дә, тәртипле дә, үткен дә, ярдәмчел, башлап йөрүче, укытучыларның ышанычлы таянычы да булды. Пионер эшендә актив катнашты, отряд советы председателе итеп сайланды. Ул мәктәпнең горурлыгы иде. Ә аннары авылыбызның гына түгел, бөтен Татарстанның горурлыгы булды. Талантын һаман үстерә барып, зур дәрәҗәгә ирешә. Мәктәптә укыгында мәктәп балалары белән уздырылган концертлар, бәйрәмнәр Вафирәдән башка узмады. Ул башлап йөрде. Бер концертта Вафирәнең биюенә, җырлавына сокланып, укытучы Зәйнәп апа әйтеп куйды: “Синең бу кызың (ул вакытта пионерлык эше белән мин җитәкчелек итә идем) югары китәчәк”, -диде. Белеп, сизеп, алдан күреп әйткән. Вафирә югары үрләр яулады, җырлары белән океан артына



барып җитте. Ул безнең Камай авылын дөньяга таратты, татар милләтенең бер вәкиле булып Камай авылын Америкага алып барды. Вафирә сәхнә дигән биек мөнбәрнең бөеклеген, дәрәҗәсен тагын да күтәрде, бизәде. Моңы гына түгел, үз-үзен тотышы, киенү рәвеше, тыйнак-ипле хәрәкәтләре сәхнәне генә түгел, бөтен тамаша залын ямьләндерә иде. Менә ул сәхнәгә чыга. Аннан матурлык, миллилек бөркелә. Тамашачыларның йөзенә сокланулы елмаю иңә, сәхнә яктырып китә, аннан залны таң калдырып, моң агыла башлый. Яңгыравыклы, көчле тавыш залны иркәли, күңелләрне тетрәндерә... Батулла әйткәндәй, “Бирсә бирә икән Ходай Тәгалә матурлык белән бергә сәләтне өеп.”

Вафирә юк-бар җырлар җырламады, аның хәзинәсендәге җырлар югары кимәлдәге җырлар-җәүһәрләр иде. Ул безнең милли горурлыгыбыз.Гореф-гадәтләребезгә һәрвакыт тугрылыклы булды. Аның башкару осталыгы гаҗәпкә калдыра, тетрәндерә, каян килә икән ул моң! Ул җырлаган “Кызарып кояш чыкканда” дигән җырны башка беркем дә аның кебек башкара алмый. Камай кызы Татарстанның атказанган артисткасы, җырчы Рәмзия Зиннатуллина башкарган “Бөдрә таллар”ны да башка җырчылар җырлап-җырлап карыйлар да, Рәмзия “Бөдрә таллары” чыкмый шул. Вафирә киң колачлы артистка иде. Ул ШТМ ның да иң актив катнашучыларның берсе була. “Бер ШТМ (Шаяннар, тапкырлар мәҗлесе) да Вафирәдән башка узмый иде, - дип яза Батулла. Ул ШТМчыларны шаккатырып Габдулла Тукайның “Су анасы” шигырен сөйләгән. Мин шуңа куандым: Вафирә үзенең беренче укытучысы Маһруй апа Тимеркәевадан күп нәрсә өйрәнгән икән. Маһруй апа “Су анасы” шигырен бик оста сөйли иде. Менә ул авыл малае сәхнәгә чыга, яланаяк, чалбарының бер балагын сызганып куйган, башында кәләпүш, өстендә ак күлмәк, түше ачык. Тиешле интонация белән, гаҗәпләнгән, куркып калган кыяфәттә шигырьне сөйли башлый. Тамашачылар да су анасының үзен күргәндәй тыңлыйлар.

Әйе, мәктәп киң дөньяга чыгу өчен старт мәйданы, башлангыч пункт. Күп нәрсә укытучыдан тора. Ул һәрьяклап үрнәк булырга тиеш. Димәк, күренекле затларның: галимме ул, җитәкчеме, педагогмы, артистмы, башка һөнәр иясеме – аңа уңышлы орлыкларны укытучы чәчкән. Вафирә турында уйлыйм да аңа эндәшәм:

- Рәхмәт сиңа минем укучым булганың өчен, синдәй балаларны укыту үзе бер бәхет; рәхмәт сиңа чын сәнгатькә, матурлыкка хезмәт иткәнең өчен, рәхмәт Камай авылын дөньяга таратканың өчен; рәхмәт милләтебезне саклап, татар халкының күркәмлеген җиһанга таратканың өчен.

Бу сүзләремне Вафирә үзе ишетсә иде... юк шул инде, соңга калдым. Рәхмәтем, әйткән сүзләрем аңа дога булып барсын. Урыны җәннәттә булсын.

P.S. Вафирә кебек тамашачыларны да, үзен дә хөрмәт итүче, сәхнә тотучы әдәпле, талантлы җырчыларны көтәбез.

“ӘДӘП”нең мәгънәсе, аңлатмасы һәр заманда да бер үк төрле.

## Хуш, Вафирә.

***Камил Гыйльмуллин,*****“Менделеев яңалыклары”, 19 октябрь, 2001 ел.**

Вафирәкәем, син балалар бакчасына йөргәндә, җырлавыңны тыңлап хәйран калган идем. Укытучы-бертуган Мәсхүдә апам: “Бүген укытучы итеп куй, ул эшли беләчәк”, - дигән иде.

Җидееллык мәктәпне “отлично”га тәмамлап, Алабуга мәдәният-агарту училищесына киттең, җырың-моңың белән, район һәм республика

олимпиядаларында катнашып, беренчелекне яуладың. Училищены тәмамлап, туган авылың Камайга клуб мөдире булып кайттың. Ул вакытта авылыбыз моңың, җырың белән гөрләп торды. Синең җырың Казаныбыз халкын шаккаттырды. “Батыр кул” колхозы үзенең махсус стипендиясен билгеләп, сине Казан музыка училищесына озатты. Инде беренче курстан ук Татарстан радиосыннан җырларыңны халык күңеленә сала башладың.

Училищены тәмамлагач кияүгә чыктың. Туеңны Түбән Камада үткәрдек. Шәһәрнең 1 нче музыка мәктәбен оештыруда зур көч куйдың, балалар укыттың.

Талантыңа сокланган композитор Нәҗип ага Җиһанов сине консерваториягә әйдәде. Укыдың. Менә дигән җырчы булдың. Илләр, кыйтгалар гиздең, шөһрәт казандың. Син – милләтпәрвәр, татар халкының сакчы абыстае, абыстайларның да иң талантлысы, усал, кыюы, гаделе, мәрхәмәтлесе дә һәм иң күңеллесе дә идең.



Үзең үстергән куакка
Сайрадың басып.
Милләт корабын тарттың син,
Иңеңә асып.

Җырыңны җырладың һәрчак
Моңыңа төреп.
Ник яттың әле бик иртә
Бу гүргә кереп?

Кеше китә, җыры кала,
Моңнарың чыңлый.
Вафирәкәй, җырларыңны
Халкыбыз тыңлый,
Милләтләр тыңлый.
Каеннар җылый.

Безгә бик ямансу булыр
Яз, җәй,көз, кышын.
Киттең шул, кайтмаска киттең,
Сөйгән аккошым.




**Соңгы сүз.**

Җырчы – халыкның иң кадерле баласы. Моңлы баласы. Сагышлы баласы. Татар халкының нәкъ шушы баласы иде Вафирә. Аның фаҗигале үлеме бар татар дөньясын тетрәндерде. Җырчыны соңгы юлга озатырга меңләгән кеше килде. Моңлы сандугачыбыз сайраудан, челтер чишмә агуыннан туктады, гүзәл аккош күкләргә - Киек каз юлы тарафына юл алды, кыю бөркетнең канатлары каерылды...

Әмма хәтер яши. Хәтер барда аны оныту мөмкин түгел.

Хуш, Вафирә, бәхил бул. Урының җәннәт түрләрендә булсын. Сине, җырларыңны яраткан халкың, якташларың онытмас. Йөрәкләрдә сиңа карата беркайчан да әйтелеп бетмәячәк рәхмәт хисе яшәр.

Ә бу җыентык мәктәпләрдә, мәдәният йортларында Вафирә Гыйззәтуллинага багышланган тематик кичәләр, концертлар, бәйгеләр үткәргәндә куллану өчен ярдәмлек, райондашларыбызга, аны белгән һәм хөрмәт иткәннәргә былбыл сандугачтан

соңгы

моңсу

ядкарь

булыр дип ышанып калам.

**Автор.**

**Этот текст для автографа на внутренней стороне обложки.**

***Чын күңелемнән ___________________________________________***

***сөекле җырчыбыз Вафирә Гыйззәтуллина турында истәлек – ядкарьне бүләк итәм.***

***2016 ел, февраль.***